• ВАКЫЙГА •
БЕРЬЕЛЛЫК УРАЗА
3 бит

• ВӘГАЗЬ •
КҮРКӘМ ӘХЛАК – ЯШӘҮ РӘВЕШЕ
6 бит

• САБЫЙГА •
КЕШЕ – ИҢ МӘРТӘБӘЛЕ ЗАТ
9 бит

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
ӘНИ ДИМИМ...
14 бит

№ 5 (298) | Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы | шәүвәл 1441

Май, 2020

# دين ومعيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ



## ШӘҮВӘЛ АЕНДАГЫ АЛТЫ КӨН УРАЗА БЕР ЕЛГА ТИҢ?

Безнең күбебезнең шәүвәл уразасы турында ишеткәне бардыр. Һәм күпләрне бу ураза өчен әҗер-савап таң калдыра.

Шәүвәл аеның беренче көненә Ураза гаете туры килә. Шуңа күрә бу көндә ураза тотылмый, ә инде 2нче шәүвәлдән бу нәфел уразасын тота башларга була. Бу ураза Пәйгамбәребезнең сөннәте булганга күрә, без үзебезне Мөхәммәд галәйһиссәламгә якынайтабыз.

Һәм бигрәк тә, шушы уразаларны тоту Кыямәт көнендә аның шәфәгатенә ирешергә бер сәбәп булып торса иде.

Дәвамы 3 нче биттә

# Ютазыда янган мәчеткә төзекләндерүдән соң ярымай куелды



20нче май көнне, Рамазан аеның 27нче көнендә Ютазы районының Иске Каразире авылында иртәнге сигездә (08:00), үз-үзеңне читләштерү режимы вакытында янган мәчет манарасына ярымай кую тантанасы узды. Әлеге чарада Ютазы районы имам-мөхтәсибе Марат хәзрәт Мәрданшин, район башлыгы Аяз Шәфигуллин, Ютазы районы имамнары, "Фәнис" мәдрәсәсе мөгаллимнәре һәм остазлары, район халкы катнашты.

Ярымай куелыр алдыннан имам-мөхтәсиб Марат хәзрәт Мәрданшин Коръән-Кәрим аятьләре укыды һәм мәчетне торгызу эшләрен уңышлы төгәлләү хөрмәтенә җәмәгать белән дога кылды. Исегезгә төшерәбез, Рамазан ае дәвамында, акча җыю игълан ителеп, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды мәчетне торгызу өчен 750 000 сум күләмендә акча җыя алды.

Исегезгә төшерәбез, 4 апрель көнне Ютазы районы Иске Каразирек авылы мәчетендә янгын чыгып, 2002 елда төзелгән агач бина тулысынча диярлек янып бетте. Мәчет ике авыл халкы өчен хезмәт иткән була. Бер айдан аз гына вакыт эчендә мәчет сип-панельләр технологиясе буенча яңадан төзелде. Бүгенге көндә мәчетнең стеналары бар, ишек, тәрәзәләр куелган, идән җәелгән инде. Якын көннәрдә әйләнә-тирәне җыештыру, төзелеш калдыкларыннан чистарту эшләре башкарылачак. Шулай итеп, барлык эшләрне 30 майга эшләп бетерү ниятләнә.

Хөрмәтле мөселманнар, дин кардәшләребез! Мәчетне төзекләндерүгә керткән ярдәмнәрегез өчен киң рәхмәтләребезне җиткерәбез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Кош оясы хәтле зурлыкта мәчет төзүчегә дә Аллаһы Тәгалә Җәннәттә йорт төзер».


■ dumrt.ru

# Туган тел елы кысаларында Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең тормыш юлы турында татарча китап бастырылды

**Казанда "Аллаһының сөекле расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм" дип исемләнгән китап дөнья күрде. Аның авторы – күренекле татар мөселман әһеле, Казанның "Миргазиян" мәчете имам-хатыйбы Габдеррәүф хәзрәт Зәбиров.**

Китапта татар телендә Мөхәммәд галәйһиссәлам гомеренең Мәккә чоры турында сөйләнә: тууы, балачагы, үсмер һәм яшьлек еллары, Мәдинәгә күченгәнче пәйгамбәрлек вазифасы турында бәян ителә. Китап башлангыч, урта һәм югары белем алу йортларында уку әсбабы буларак тәкъдим ителә, басма белән киң катлам укучылар да файдалана ала. Китапны әзерләгәндә автор Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең тормыш юлын тасвирлаган төрле чыганаклар кулланган, зур әзерлек һәм нәшер итү процессы аша узган. Габдеррәүф хәзрәт әйтүе буенча, бүгенге көнгә кадәр татар телендә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең тормыш юлын тасвирлаган бары биш китап чыккан булган, аларның дүртесе Казанда инкыйлабка кадәр, берсе – постсовет чорында дөнья күргән. Арасында: "Хәяте Мөхәммәд" (Казан, 1911, авторы Закир Кадыйри (1878-1954)); «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм» (авторы Ризаэтдин Фәхретдин (1859-1936), 1909 елда Казанда "Вакыт" гәҗите типографиясендә чыккан), «Хәзрәти Мөхәммәд» (1914 елда чыккан, авторы Сөнгатулла Бикбулат (1886-1955)), "Аср сәгадәт" (Казан, 1909 ел, авторы Шәһәр Шәрәф), «Пәйгамбәребез Мөхәммәд» (Казан, 1999 ел, авторы Фәрит Зәкизҗанович Яхин).

Гыйлемле булу сәбәпле, халкыбызга гарәп һәм фарсы телләрендә язылган китаплар да аңлаешлы булган. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең тормышыннан кайбер вакыйгаларны искә алган ислам җыентыклары да чыккан, мәсәлән, Каюм Насыйриның "Мәҗмәгыль әхбар. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам тормышы", дигән хезмәте, дип аңлатып китте хәзрәт. Хәзер исә Казанда исәп буенча алтынчы шундый китап дөнья күрде. Бу басма ТАССРның барлыкка килүенең 100еллыгына багышланып һәм Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән Туган тел елы кысаларында нәшер ителде.




Искә төшереп узыйк, быел Диния нәзарәтенең гыйнвар аенда узган Пленумында 2020 елны Татарстан Республикасында Туган тел елы итеп игълан итәргә бердәм тавыш бирелде. Шулай итеп, мөфтиятнең һәм аның кул астындагы оешмаларының эшчәнлеге агымдагы елда мәчетләрдә татар мохиты үсешенә, татар телен өйрәтүгә, татар дини мирасын популярлаштыру, милләтне саклап калу һәм ватандашларыбыз арасында милли үзаң үстерүгә карап корылган.

Татарстан Республикасы Президенты 2019 елның 25 сентябрендә чыккан № УП-572 Указы белән Татар автоном Совет Социалистик Республикасының оешуына 100 ел тулуга багышлап, республикабызның барлыкка килү тарихы һәм күтәрелешенә киң катлам җәмәгатьнең игътибарын җәлеп итеп, 2020 ел Татарстан Республикасында ТАССРның барлыкка килүенә 100еллыгы елы дип игълан ителде.

■ dumrt.ru

# Берьеллык ураза

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан уразасыннан соң шәүвәл аенда алты көн ураза тотучыга тулы ел дәвамында ураза тоткан кебек савап булыр», – дип әйткән. Шәүвәл аенда ураза тоту Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте булып тора һәм Рамазан аенда ураза тотып, бу айда да ураза тотучы – бер ел буена ураза тоткан кешегә тиң булачак.

Әлбәттә, шәүвәл аенда гына ураза тотып, кешегә берьеллык ураза савабы язылмас. Аның өчен фарыз ураза – Рамазан уразасы да кирәк, чөнки һәр изге гамәл өчен әҗер-саваб 10 тапкыр арттырылып языла. Рамазанның һәр көне өчен 10ар саваптан гына да – 300 көн була. Ә шәүвәлнең 6 көне – 60 көн. Елына ураза тотарга мәкруһ булган 5 көн бар: Ураза гаете һәм Корбан гаетенең 4 көне. Шулай итеп, Рамазанга өстәп токткан бу ураза – 1 еллык уразага тиң була.



### Шәүвәл уразасын тоту тәртибе

Шәүвәл ае уразасын ни рәвешле тоту – кешенең үз ихтыярында. Рамазанның һәр көнендә ураза тоту фарыз булса, шәүвәл уразасы бу айның теләсә кайсы көнендә тотыла ала, ягъни алты көн рәттән дә, төрле көннәрдә дә ярый.

Медицина күзлегеннән караганда, Рамазанга кадәр дә ураза тотып, организмыбызны ияләштергән кебек, Рамазаннан да акрынлап чыгу (шәүвәл уразасын тотып) хәерлерәк булачак.

# Болгар ислам академиясендә кабул итү кампаниясе старт ала

Болгар ислам академиясе “Дини оешмалар өчен дин әһелләре һәм хезмәткәрләр әзерләү” юнәлеше буенча магистратурага һәм докторантурага укырга керү өчен абитуриентлар кабул итә.

Академия – югары белем бирү оешмасы. Бирeдә ислам белгечләре – магистрлар һәм докторлар әзерлиләр. Уку тулысынча түләүсез, ул рус һәм гарәп телләрендә алып барыла. Студентлар һәм мөгаллимнәр заманча кампусның уңайлы бер урынлы номерларында бушлай яшиләр, дүрт тапкыр бушлай тукланалар, шулай ук Академия эмблемасы төшерелгән югары сыйфатлы көндәлек һәм парад киеме алалар.

Академия студентлары кызыклы һәм вакыйгаларга бай тормыш белән яши. Алар өчен мәдәни-массакүләм, спорт чаралары үткәрелә. Ел саен студентлар БГӘ, Мисыр, Төркия, Марокко, Үзбәкстан, Таҗикстан һ.б. чит илләрдә стажировкалар уза. Студентларның Рәсәйкүләм һәм халыкара дәрәҗәдәге конференцияләрдә, мәдәни-массакүләм чараларда катнашуы һөнәри үсешкә, үзүзеңне тормышка әзерләргә һәм фәнни эшчәнлек алып барырга ярдәм итә.

2019 елны Академиядә докторантура белем бирү программасы буенча икееллык курстан соң Рәсәйдә беренче тапкыр докторлык диссертацияләрен яклау узды. 6 чыгарылыш укучысы, фәнни хезмәтләрен уңышлы яклап, ислам фәннәре докторы исемен алды.



Магистратурага керү өчен дөньяви яки дини югары уку йорты (Рәсәй яки чит ил) бакалавры дипломы, шулай ук гарәп телен һәм ислам нигезләрен белү мәҗбүри. Уку вакыты – өч ел.

Докторантурага укырга керү өчен югары белем алу хакында дөньяви яки дини (Рәсәй яки чит ил) вузы магистры дипломына ия булу, шулай ук керү имтиханнарында алга таба язылачак докторлык диссертациясе темасына гарәп телендә реферат язарга кирәк. Уку вакыты – ике ел.

Документлар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Казан ш., Гоголь ур., 3 а.

### Кирәкле документлар исемлеге:

– үзәкләштерелгән дини оешмадан тәкъдим итү хаты;
– билгеләнгән үрнәктәге гариза;
– анкета;
– белем алу турында документ (күчермә);
– паспорт (күчермә);
– 3х4 форматтагы 6 фотография;
– 086/у медицина белешмәсе.

Рәсәйдәге эпидемиологик вәзгыятькә бәйле рәвештә, академия сайтында “Личный кабинет абитуриента” онлайн сервисы эшли, анда укырга керүче, өйдән чыкмыйча гына, барлык кирәкле документларны кабул итү комиссиясенә тапшыра ала. Әлеге сервисны bolgar.academy адресы буенча “Приемная кампания” бүлегендә табарга мөмкин. Алга таба абитуриентның шәхси кабинетына күчәргә кирәк.

Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе: Нуриев Ринат Салават улы, моб.: +7 (917) 229-55-77, e-mail: priem@bolgar.academy.

■ dumrt.ru

# Туганлык җепләре

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәрим китабында болай дип әйтә:

**«И, кешеләр! Сезне бер җаннан (Адәмнән) яраткан, аның бер кисәгеннән (булган сул кабыргасының иң астыннан Хәвва исемле) ишен яраткан һәм аларның икесеннән бик күп ирләр белән хатыннарны халык кылып (җиһанга) тараткан Раббыгыздан, Аның исеме белән бер-берегездән үтенә торган Аллаһыдан (Аңа каршы баш күтәрүдән) һәм туганлык җепләреннән (аларның өзелүеннән) куркыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – сезне Күзәтүче».**

«Нисә / Хатыннар», 4:1

Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә бу аятьтә берничә әйбергә басым ясый, аерым алганда, кеше бары Аллаһыдан гына куркырга һәм туганлык җепләрен сакларга тиеш. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә «Нисә» сүрәсен ике төрле боерыктан башлап, туганлык җепләрен саклау әмерен бик югары күтәрде. Ни өчен? Кешенең бик көчсез зат икәнен белгәнгә күрә. Мәсәлән, мирас бүлешкәндә талашып, кычкырышып беткән туганнар азмы? Яшь бара-бара бер-берсен оныта башлаган туганнар азмы? Юк, җәмәгать! Ә бит берәр авырлык килгәндә иң беренче булып туганнарга чабабыз, ярдәмне алардан өмет итәбез. Нинди генә дуслар, танышлар булмасын, туганнар аларга караганда якынрак. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәрим китабында болай дип әйтә:

**«Араларында кардәшлек якынлыгы булган кешеләр Аллаһы хөкемендә бер-берсенә варислардыр».**

«Әнфәл / Табыш», 8:75

Ягъни мөселман – мөселманга кардәш. Әмма кан кардәшең, үз туганың аларга караганда да якынрак икән. Шуңа күрә мөселман кешесенең намаз уку, ураза тоту, әти-әниგә игелекле булу кебек вазифалардан тыш тагын бер вазифасы – туганлык җепләрен саклау, аларны өзмәү. Моны Аллаһы Тәгалә Үзе боера. Шулай ук Пәйгамбәребез дә: «Аллаһы Тәгаләгә һәм Кыямәт көненә иман китергән кеше туганлык мөнәсәбәтләрен сакласын», – дип әйтә.

### Кемнәр соң безнең якын туганнарыбыз?

Иң якыннары – әтиләребез, әниләребез, бабайларыбыз, әбиләребез, балаларыбыз, оныкларыбыз һәм оныкчыкларыбыз. Аннан соң якындагы туганнар, апа-сеңелләр һәм аларның балалары, аннан соң әтиәниләр буенча абыйларыбыз һәм апаларыбыз, аларның балалары, аннары абыйлары һәм апалары, аналар нәселе буенча апалары һәм аларның балалары һ.б. Моның шулай икәнен Пәйгамбәребез белән булган түбәндәге вакыйга да раслый: «Бервакыт бер кеше пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Аллаһының Илчесе, мин кемгә карата иң зур ихтирам, хөрмәт күрсәтергә тиеш?» – дип сорагач, ул: «Әниеңә», – дип җавап бирә. Мондый сорау тагын ике тапкыр кабатлана. Инде шушы кеше дүртенче тапкыр да шулай дип сорагач, Расүлебез галәйһиссәлам: «Аннары әтиеңә, аннан якынрак булганнан башлап туганнарыңа (хөрмәт күрсәтергә тиеш)", – дип җавап кайтара (Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

### Туганнар белән элемтә нык булсын

Туганлык җепләрен өзгән очрак өчен кодси хәдистә болай дип әйтелә: «Мин–Аллаһы, һәм Мин–Мәрхәмәтле һәм Мин туганлык бәйләнешларын төзедем, аларга Иминлек исеменнән исем бирдем, һәм берәү ул араларны саклый икән, Минем белән элемтәне саклый, ә кем аларны өзә, Минем белән дә элемтәне өзә" (Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

Туганнар белән элемтә көчле булырга тиеш дидек. Әмма бүгенге көндә безнең арада коры кешеләр дә юк түгел. Алар өчен туганнар да, дуслар да, бу дөньяда табыш алу исулы кебек кенә кабул ителәләр. Әмма туганнар белән элемтә ниндидер килешү нигезендә булырга тиеш түгел. Туганнарны якын итүнең күп ысуллары бар, мәсәлән: кеше үз туганнарын күрергә, аларга бүләкләр бирергә, аларның эшләре һәм проблемалары белән кызыксынырга, алар арасыннан ярлыларга ярдәм итәргә, ягымлы һәм мәрхәмәтле мөнәсәбәтләрне сакларга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә тиеш. Шулай ук аларны кунакка чакырырга, аларга кунакчыллык күрсәтергә, уңышларына сөенергә, кайгы-хәсрәтләренә борчылырга, алар өчен Аллаһы Тәгаләдән игелек сорарга кирәк. Кеше аларга карата көнчелек хисе тоярга тиеш түгел, аның йөрәге һәрвакыт ачык булырга һәм аларга бернинди начарлык эшләмәскә тиеш. Әгәр алар чакырсалар, чакыруга җавап бирергә һәм алар авырганда аларның хәлен белергә кирәк. Шулай ук кардәш-ыруларны Исламга чакыру һәм аларны туры юлга өндәү һәм харамнардан кисәтү зур әһәмияткә ия. Ибне Әбү Хәмзә рахимәһуллаһ: «Кайвакыт туганлык бәйләнешларын тоту акча ярдәмендә, ә кайвакыт ярдәм кулы сузу аша була», – дип әйткән.

Шунысы да мөһим: туганлык җепләрен саклау – сиңа карата яхшы мөгамәләдә булган туганың белән генә түгел, ә синең белән араларны өзгән туганыңа карата булган мөнәсәбәттә дә нык булырга тиеш.



Әгәр берәүгә туганы шалтыратмый, аны искә алмый, хәлләрен белешми, игътибар күрсәтми икән, ул кеше үзе икесе арасында яхшы мөнәсәбәтләрне саклауда өлешен кертергә тиешле. Хәтта аңа карата явызлык кылсалар да, туганнар – мөселманнар булмаса да, Аллаһы Тәгалә хакына сабырлык сорарга һәм гафу үтенергә кирәк. Хисап тоту көнендә һәркем үзенең кылган гамәлләре өчен генә үч алыр: игелекле гамәл кылучыга әҗер чыгар, яманлык кылучыларга һәм залимнәргә җәза бирелер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам түбәндәге сүзләрне әйткән: «Сиңа яхшы мөнәсәбәттә булган туганыңа игелек белән җавап бирүең – әле аңа карата булган туганлык бурычыңны үтәми, ә синең белән мөнәсәбәтен өзүенә карамастан, ул туганыңа яхшы мөнәсәбәттә булуың – туганлык бурычыңны үтәвеңнән була».

### Туганнар – безнең якыннарыбыз

Халкыбызда туганнар хакында мәкаль-әйтемнәр дә шактый, мәсәлән: «Тату туганнар таштан коймa корганнар», «Туган бар җирдә ярдәм бар».

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

**«Һичшиксез, Аллаһы (һәрнәрсәне аңлатыр өчен иңдергән китабында) гадел булырга, изгелек кылырга һәм (бигрәк тә) якын туганнарга (мохтаҗ булган нәрсәләрен) бирергә (һәм туганлык җепләрен ныгытуны) әмер итә».**

«Нәхел / Умарта кортлары», 16:90

Мөгаен, һәркем үз гомерендә якын туганнарыннан башка берәүнең дә аңа ярдәм кулы сузмаячагына инангандыр. Шуңа күрә балаларны балалар йортларында, картларны картлар һәм инвалидлар йортларында калдыру модасын онытырга кирәк. Туганлык бәйләнешларының өзелүе – зур гөнаһларның берсе. Изге Коръән аятьләрен һәм Пәйгамбәребез хәдисләрен түбәндәрәк китерәчәкбез.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәрим китабында болай дип әйтә:

**«(И, коллар!) Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә ширек кушмагыз. Ата белән анага, (бертуганнар һәм агалар кебек) якыннарга, ятимнәргә, мескеннәргә, (нәселдәшлек яки яшәгән урыны җәһәтеннән) якын күршегә, (нәселдәшлеге яки өе) ерак күршегә, (ир-хатын, юлдаш һәм сабакташ кебек) янәшәдәге иптәшләргә, юлда калучыга һәм уң кулыгыз ия булган нәрсәләргә (коллар, җарияләр һәм хезмәтчеләргә) игелек кылыгыз. Һичшиксез, Аллаһы тәкәббер (булганы өчен туган, кардәш һәм күршеләренә карата яхшы мөнәсәбәттә тормаган) һәм (өстенлекләрен санаган) мактанчык кешеләрне сөйми».**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Аятьтән күренгәнчә, кан кардәшләребез белән генә түгел, дин тотуларына яки тотмауларына карамыйча, туганнарыбыз, күршеләребез, дусларыбыз һәм хезмәттәшләребез белән дә мөнәсәбәтләрне ныгытырга кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакыт үзенең сәхабәләренең хәлләре белән кызыксына, аларны кайгыртып тора иде. Элекке заманнарда кешеләр дусларына янына килү өчен чүлне кичкәннәр. Бүген исә бу мәсьәлә күпкә җиңеләйтелгән: вакыт булмаса да, кеше белән теләсә кайсы илдә, теләсә кайсы вакытта сөйләшергә мөмкин һәм сөйләшергә генә түгел, үз телефоныңның экраннары аша да күреп аралашырга була.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә, мөселманнар! Туганлык бәйләнешләрен саклагыз, бу – тормышны озынайта һәм ризыкны арттыра», – дип әйткән. Шушы изге гамәлне барыбыз да эшләргә тырышсак иде.

■ **Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев, Хәсәншәех авылы имам-хатыйбы**

# Муса галәйһиссәлам кыйссасы

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

## Фиргавеннең үлеме

Әлбәттә, исраиллеләрнең китүе билгеле булгач, фиргавен шунда ук гаскәр җыя һәм алар артыннан куып китә. Фиргавен һәм аның баш вәзире Хаман җиде йөз меңлек гаскәрнең башында тора. Һәр яугирнең башында махсус баш киеме (шлем), кулларында сөңге була. Кояш чыкканда Фиргавен үзенең гаскәрләре белән Муса галәйһиссәлам халкы янына килеп җитә. Фиргавенгә исраиллеләрнең саны аз кебек тоела һәм ул болай дип әйтә:

**"Һичшиксез, алар бит аз санлы бер көтү генә".**

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:54

Ә Муса галәйһиссәлам халкы фиргавенне һәм аның гаскәрләрен күргәч, зур куркуга төшә, чөнки алар диңгез буена килеп җиткән була һәм чигенергә урыннары калмый. Коты очкан халык Муса галәйһиссәламгә болай дип әйтә:

– Ий Муса! Алар безне куып җитеп баралар. Без бүген һәлак булачакбыз. Әгәр дә без диңгезгә керсәк, һичшиксез, батып үләчәкбез. Безнең артта Фиргавен гаскәрләре тора, әгәр алар безне куып җитсәләр, барыбызны да үтерәчәкләр. Ий Муса! Безгә нишләргә? Әгәр дә безгә һәлак булырга язган икән, безне Мисырдан алып чыкмаска кирәк иде, анда һәлак булуыбыз яхшырак булыр иде.

Аларга җавап итеп Муса галәйһиссәлам болай дип әйтә:

**«Ул (Аллаһының вәгъдәсенә ышанып): "Юк! (Алар безне һич тота алмаслар! Аллаһы хакында начар уйламагыз!) Һичшиксез, Раббым минем белән бергә, Ул (котылуыбыз өчен) миңа юл күрсәтәчәк!" – диде».**

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:62

Аннары Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә:

**"Таягың белән диңгезгә сук!"** – дип әмер биргән.

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:63

Муса галәйһиссәлам таягы белән диңгезгә суккач, халык каршындагы диңгез чигенә. Муса галәйһиссәлам халкы каршында уникe юл ачыла. Диңгез төбе буйлап үткән бу аралыкка Аллаһы Тәгалә кояш һәм җил җибәрә, алар үтәр юлны тулысынча киптерәләр. Шулай итеп исраиллеләрнең һәр кабиләсе үз юлы буйлап китә. Аралыкның ике ягында тау кебек биек булып диңгез суы тора һәм ул судан эшләнгән дивар кебек түгел, ә бетоннан эшләнгән кебек хәрәкәтсез була.

Кабиләләрнең һәрберсе үз юлы буенча бара һәм башка кабиләләрне күрми. Шуңа алар тагын Муса галәйһиссәламгә мөрәҗәгать итәләр:

– Нишләп без башкаларны күрмибез? Бәлки алар инде батканнардыр һәм һәлак булганнардыр?

Муса галәйһиссәлам аларга:

– Алга барыгыз! Алар сезнең кебек үк үз юллары белән баралар, – дип әйтә.

Аңа җавап итеп исраиллеләр:

– Без дусларыбызны күрми торып канәгать була алмыйбыз, – диләр.

Шунда Муса галәйһиссәлам Аллаһыга мөрәҗәгать итеп сорый:

– Ий Аллаһы! Миңа боларның юньсез холыкларына каршы ярдәм күрсәтсәңче!

Шуннан соң Аллаһы Тәгалә: "Таягың белән уң якка сук!" – дип аңа вәхи иңдерә. Муса галәйһиссәлам шуны эшләгәч, уникe юлны бер-берсеннән аерып торган су массивларында тәрәзәләр барлыкка килә һәм кешеләр бер-берсен күрә һәм ишетә алу мөмкинлегенә ия булалар. Шулай итеп, Муса галәйһиссәлам халкы диңгез төбе аша үтеп, аның икенче ярына барып чыга.

Бу вакытта фиргавен үз гаскәре белән диңгез төбендә ачылган юлга килеп җитә. Икегә аерылган диңгезне күреп, фиргавен үз халкына:

– Минем бөеклекне күреп һәм мин үз колларымны куып тотар өчен диңгез икегә аерылды, – дип әйтә.

Ләкин аның бер генә кешесе дә диңгез төбенә керергә теләми. Фиргавен кешеләре куркып:

– Әгәр дә син Раббы икәнсең, Муса анда кергән кебек, син дә бу юлга кер, – дип әйтәләр.

Ләкин фиргавен дә диңгез төбенә керергә кыймый. Бу көнне ул үзе дә, гаскәре дә айгырларга атланган була. Шунда Җәбраил галәйһиссәлам биягә атланып алар каршына килеп баса һәм, аның биясе артыннан фиргавен айгырлары да иярсен өчен, беренче булып диңгез төбендәге юлга керә. Фиргавеннең аты бия исенә ияреп диңгез төбендәге шул юлга атлый. Әлбәттә, алар Җәбраил галәйһиссәламне күрмиләр, тик фиргавен үз айгырын туктата алмый. Аның артыннан бу юлга аның бар гаскәре дә кереп китә.

Шул ук вакытта Микаил галәйһиссәлам атка атланып гаскәрләрнең артына баса һәм гаскәрләрне алга таба куалый башлый. Ул коры җирдә бер генә кеше дә калмавын, барысының да су төбендәге юлга кереп беткәнен күзәтеп тора.

Фиргавен халкыннан соңгы кеше диңгезгә кергәч, ә Муса галәйһиссәлам халкының соңгы кешесе диңгездән чыккач, Аллаһы Тәгалә диңгезгә аларны йотарга әмер бирә. Һәм чамадан тыш зур дулкыннар шау килеп фиргавен гаскәрләре өстендә ябылалар. Тау кебек зур бу дулкыннар кушылгач, фиргавеннең бар гаскәре суга батып үлә.

Риваятьләрнең берсендә Җәбраил галәйһиссәламнең шушы вакыйгаларга кадәр үк фиргавенгә кеше кыяфәтендә килүе тапшырыла. Ул фиргавеннән:

– Әгәр дә синең берәр колың синнән баш тартып, үзенең Раббылыгы турында игълан итсә, син аны нишләтер идең? – дип сорый.

Аңа җавап итеп фиргавен:

– Мин аны суда батырып үтерер идем, – дип җавап бирә.

Шунда Җәбраил галәйһиссәлам аңа, кул куйсын өчен, аның шул сүзләре язылган кәгазь бирә. Ул имзасын куя. Фиргавен суда батырып үтерелгәч, Җәбраил галәйһиссәлам бу кәгазьне алып килеп аның каршына куя. Ягъни, чынлыкта фиргавен үзе үк үзенә үлем карары чыгарган булып чыга.

Фиргавен батып үлгән вакытта аның күз алдындагы пәрдәләр алып ташлана һәм аңа Ахирәттә булачак урыны күрсәтелә. Һәм шунда ул:

**"Һичшиксез, мин Исраил уллары ышанган Заттан башка һичбер илаһ булмаганына иман китердем. Мин дә – (үзләрен Аллаһыга тапшырган) мөселманнарданмын!"** – дип әйтә.

«Юныс», 10:90

Мондый иман кабул ителәме соң? Бөтен чикләрне узып, үзен илаһ дип игълан иткән, һәм үзенә Аллаһының ике илчесе җибәрелгән, күпме могҗизалар күргән фиргавен Аллаһыга ышанудан баш тарта, әмма рухы тәнен бушаткан мәлдә җәһәннәмдә үз урынын күргәч, Мин Раббыга иман китерәм, мин – мөселманнардан", – дип әйтә. Аллаһы Тәгалә гомеренең соңгы мизгелендә китергән иманын кабул итми:

**"(Шулвакыт аңа әйтелде) "Хәзерме? Моңарчы (Аллаһы Тәгаләгә) каршы торган һәм (кешеләрнең иманына комачау иткән) бозыклык таратучылардан идең бит".**

«Юныс», 10:91

Башкаларның да гомерләре өзелгән чакта китергән тәүбәләре әнә шулай кабул ителмичә кала, чөнки алар фиргавен шикелле бөтен тормышын итагатьсезлектә үткәрә. Раббыбыз болай дип әйтә:

**"(Дәвамлы рәвештә) Явызлык кылган, үлем килгәч (кенә): "Мин хәзер тәүбә иттем", – дип әйткәннәргә ул (кабул ителә торган) тәүбә юк. Һәм кяфер булып үлгән кешеләргә дә (Ахирәттә кылган тәүбәләре кабул ителмәс). Әнә шулар өчен Без тилмерткеч бер газап әзерләдек".**

«Нисә / Хатыннар», 4:18

Исраиллеләр исә, фиргавен һәм аның гаскәре батып үлүгә карамастан: "Алар безне куып җитәрләр дә, үтерерләр", – дигән курку һәм борчылуларын дәвам итәләр. Шул вакытта диңгез фиргавеннең хәрби киемнәре белән бар гаскәрен һәм аның үзен ярга чыгарып ташлый. Бу вакыйгадан соң диңгез батып үлгән кешеләрнең гәүдәләрен кабул итми, аларны читкә бәреп чыгара башлый.

Алдагы буыннарга гыйбрәт булсын өчен, фиргавеннең гәүдәсе череп таркалмый, ул яр буена сәҗдә кылган халәттә чыгарып ташланган була.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**"Бүген Без синнән соң киләчәк кешеләр өчен бер аять (һәм гыйбрәт) булсын дип, сине (җансыз бер хәлдә, ләкин бөтен) бәдәнең белән коткарачакбыз". (Менә бу кыйссада нинди зур гыйбрәтләр бар) Әмма, һичшиксез, кешеләрнең күбесе Безнең аятьләребездән (алар турында фикер йөртүдән) гафилләр".**

«Юныс», 10:92

Зәмәхшәри хәзрәт бу аятькә шундый тәфсир бирә: "Без синең гәүдәңне диңгез ярына чыгарып ташларбыз. Без синең шәрә тәнеңне күп гасырлардан соң киләчәк алдагы буыннарга нәсыйхәт булсын өчен череп таркалудан саклап калырбыз".

Фиргавеннең гәүдәсе, инглиз галимнәре тарафыннан, Кызыл диңгез ярындагы комнарда табыла һәм Лондонга китерелә. Фиргавеннең үлеменә өч мең елдан артык вакыт үтсә дә, аның тәне бозылмаган, таркалмаган, хәтта чәчләре дә коелмаган. Аның гәүдәсе сәҗдә кылу халәтендә, ул бүгенге көндә Британия музеена куелган.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы мөфтие**

# Күркәм әхлак – яшәү рәвеше

Галәмнәрне юктан бар итүче, безгә җан, тән, ризык бирүче Аллаһы Тәгаләгә дан-мактаулар булсын. Бөтен галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелмеш булган Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Аллаһы Раббыбыз адәм баласына олы нигъмәт биргән, ул нигъмәт – акылдыр. Без нәрсәнең яхшы вә нәрсәнең начар икәнен аңлап, яхшылары белән исә гәмәл кылып, ә начарларыннан ерак тора алабыз. Безне бизи торган иң зиннәтле сыйфат – ул әдәп вә әхлак. Ул –иманның дәрәҗәсе югары булуның бер билгесе. Әхлакны төрлечә кулланып була, ягъни кеше никадәр ихласлы булса, шуның кадәр әхлагын камилләштерә. Аллаһының Илчесе бер хәдисендә: «Мин бу дөньяга әхлакны камил дәрәҗәгә ирештерер өчен килдем», – дип әйткән. Ягъни, Расүлебез галәйһиссәламнең шушы дөньяга килүенең төп сәбәбе булып, кешеләр арасында мәрхәмәтлелекне арттыру, бер-береңә ярату хисен тарату тора.

Без бүген пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә күп игътибар бирергә тырышабыз. Тышкы сөннәтләрен үтибез дә кебек, әмма иң зур сөннәт булган яхшы мөнәсәбәт кылуга аз игътибар юнәлтәбез. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«(Расүлем!) Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк. Аллаһы – (гөнаһларны күпләп) гафу Итүче, Рәхимле».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Әхлаклы булу – ул бөтен пәйгамбәрләрнең сөннәте булып тора. Әхлакның күп төрләре бар. Аларны карап үтик:

Аллаһы Тәгаләгә карата булган әхлак, ягъни Аллаһы Тәгаләдәнояла белү, Аның мәхлукъларына яхшы мөнәсәбәттә булу.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата әхлак күрсәтү, аның хакында сөйләшкәндә матур сүзләр кулланып сөйләү, исемен әйтүгә салават әйтү.

Әти-әнигә карата әхлак күрсәтү. Алар белән матур, яхшы итеп сөйләшү. Аларның гөнаһлы булмаган хаҗәтләрен үтәү, аларны рәнҗетмәү, борчымау. Аларны күп сөендерергә тырышу. Шунысын белү мөһим: ата-анага әхлаксызлык күрсәтүченең үзенә дә картлык көнендә әхлаксыз бала булыр.

Күршеләр, туганнар, дуслар, кардәшләр белән дә әхлаклы булырга кирәк. Дорфа вә әхлаксыз булсаң, синең янында якын кешеләр калмаячак. Әгәр дә үрнәк алырдай кеше эзлисең икән, иң беренче итеп әхлакка бай булган кешедән үрнәк алырга кирәк, чөнки бүгенге көндә сүз белән зур эшләр кылучылар күп, әмма гәмәлдә, үзенең яшәү рәвешендә күркәмлекне күрсәтүчеләр аз. Әхлак – ул яшәү рәвеше. Ул мәчеттә генә яки үзеңә кирәк кеше янында гына бик тәрбияле булып, бүтән кешеләр янында «битлек кию» булырга тиеш түгел. Синең әхлагың, синең нинди җәмгыятьтә булуыңа карап үзгәрергә тиеш түгел. Әгәр дә бу алай түгел икән, син берәүләр янында бер төрле, икенчеләр янында икенче төрле икән, димәк, әле үзеңнеңәхлагыңныкамилләштерергә кирәк. Бер генә мизгелгә үз-үзебезгә ихластан сорау биреп карыйк әле: «Кем мин?» «Әхлагым нинди дәрәҗәдә?»

Бервакыт хастаханәдә табибка чиратта торганда, ике кеше чират бүлешә алмадылар, бер-берсенә нинди генә сүзләр әйтеп бетермәделәр. Ә бит сүзләрне әйтү җиңел, әмма әйткәннән соң гафу үтенеп бетерү генә бик авыр мәсьәлә. Әхлак безнең холыкның иң күркәм ягы булырга тиеш. Ата-ана баласына бирә ала торган иң зур бүләк – ул тәрбия. Димәк, кешенең әхлак ягы да бик югары булырга тиеш. Әмма соңгы вакытларда без балалар, яшьләр арасында бу төшенчәнең бик «аксаганын» сизә алабыз. Бүгенге көндә тәртипле бала хәзинәгә тиң. Кызганыч, бүген балалар өчен төп тәрбияче булып смартфон, планшет һәм интернет тора. Мәгънәсез фильм, видео, блоглар – болар яшь буын өчен бик начар үрнәк. Чын үрнәк алыр өчен безгә Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләрне, галимнәрне, акыл ияләрен бирде. Хикмәт белән эш итүче, үзләренең гамәлләре белән дингә өндәүче остазларны үрнәк итте. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлына күз салсак, Аллаһының Илчесе әхлак һәм тәрбиясе булмаган халыкка кыска вакыт эчендә әдәплелекне, тәрбиялелекне җиткерә. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Сезнең өчен (бигрәк тә) Аллаһыга һәм Соңгы көнгә өмет баглаган һәм (курку, теләү, муллык һәм тарлык кебек бөтен хәлләрендә) Аллаһыны күп итеп искә алган кешеләр өчен Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмдә күркәм үрнәк бар».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:21

Әхлакның бер ботагы – ул дин кардәшләрга карата яхшы мөнәсәбәт.



Рамазан ае буе без уразалар тотып, бергәләшеп тәравих намазлары укыдык. Әмма кайвакыт без туганнарга, дусларга карата әхлаксызлык күрсәтәбез. Шуларның берсе – ул сәлам бирмәү яки сәламгә җавап кайтармау. Ислам дине «сәлам» сүзе белән тамырдаш булган иминлек, тынычлык сүзләре белән бәйле.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Мөселманнар бер-берсенә сәлам биреп, кулга-кул тотынышып торганда гөнаһлары коелыр», – дип әйткән. Бер мөселман икенче мөселманга кардәш, аларның бер-берсе өстендә хаклары бар. Берәү кардәшенә сәлам бирсә, ул аның сәламенә җавап кайтарырга тиеш. Без кардәшлекне калдырырга тиеш түгел, Аллаһының бәрәкәте шушы кардәшлек булуда. Без кардәшләребезнең, нинди булуларына карамастан, аларга хөрмәт, Аллаһы ризалыгы өчен ярату һәм мәрхәмәт белән карарга бурычлы. Коръәндә Раббыбыз болай дип әйтә:

**«Һичшиксез, мөэминнәр – кардәшләр. Шуңа күрә кардәшләрегезне татулаштырыгыз. (Һәр эштә булганы кебек, дин кардәшләрегезнең араларын якынайтуны да җиңелгә алуда) Аллаһыдан куркыгыз, бәлки, рәхмәт ителерсез».**

«Хуҗүрат / Бүлмәләр», 49:10

Сәламне бирү, сәламне кайтару мөселманнар арасында бик саваплы эш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер бәдәви гарәбе килеп берничә сорау биргән. Иман дәрәҗәсенең иң камил рәвешенә ирешү юлын да сораган. Расүлебез галәйһиссәлам: «Син үз холкыңны яхшырт һәм иман дәрәҗәсенең, ягъни тәкъвалыкның иң олы дәрәҗәсенә ирешерсең», – дип әйткән. Күркәм холыкка ирешер өчен бердәм булып, Аллаһы яраткан затларны ярату зарурдыр. Кызганыч ки, әллә дөнья малына алданып, әллә сәлам бирүнең мөһимлеген аңламыйча, намаз тәмамлануга мәчетләрдән чыгып чабарга тырышабыз. Кардәшләргә сәлам биреп чыксак, аларның хәл-әхвәлләрен сорашсак, үзебезнең күңелдә мәхәббәт булдырыр, өстәвенә кардәшебезнең кәефен күтәрер идек, ә бу инде үзе бер зур әҗер. Якын кешеләргә берничә минут вакытны багышлаудан зарар булмый. Бәлки шушы кешеләрнең берсе белән арабызда салкын мөнәсәбәт булып, аның белән бу дөньяда соңгы тапкыр күрешүдер. Ә безнең арадагы салкынлык исә Кыямәт көненә кала, Аллаһы Үзе сакласын. Бергә кылынган догалар, бирелгән сәламнәр сәбәпле Аллаһы Раббыбыз безгә җәннәт әҗерләрен бирер. Инде мәчетләрдә исәнләшмибез икән, бүтән җирдә ничек сәламләшәбез инде без? Аллаһы Тәгаләне ярату хакында тәкърарлыйбыз, ә үзебез сәламгә дә җавап кайтармыйбыз. Үзебез мөэмин-мөселман саныннан булырга телибез, ә гади генә сыйфатларны булдырырга теләмибез. Алай була алмый! Без Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сөннәтен торгызып, арабызда мәхәббәт булдырырга тиешбез. Аллаһы юлында күп көч куючы гына олы дәрәҗәгә ия була. Җәннәтле булу өчен безнең бөтен мөмкинчелек бар, тик без боларны аз кулланабыз. Аллаһы коллары икәнебезне таныдык икән, әзрәк кенә булса да үзеңне төзәтү зарурдыр. Аллаһыны, Аның Расүлен яратып, алар яраткан эшләрне эшләмәү, бу яратуның никадәр зәгыйфь икәнен күрсәтә. Аллаһы Раббыбыз безгә бу дөньяда да һәм Ахирәттә дә кардәшлек, мәрхәмәтлелек сыйфатларын бирсә иде, ике дөньяда да җәннәт әһелләре саныннан булуны насыйп кылса иде. Әмин.

**■ Алмаз хәзрәт Галимҗанов, Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмче, Сатыш авылы имам-хатыйбы**

## Ахшам намазының ике рәкәгать сөннәте әүвәбин намазы саналамы?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Ахшам намазының ике рәкәгать сөннәте әүвәбин намазының бер өлеше саналамы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә ахшам намазыннан соң укыла торган алты рәкәгать намаз искә алына. Бу намазның саваплары турында төрле чыганакларда төрле фикерләр бар: намазның савабы 20 ел намаз уку савабына тиң, гөнаһлар кичерелә, бу намазны укучы гөнаһларыннан тәүбә итүчеләр рәтендә булыр һ.б.

"Әүвәбин" сүзе Аллаһыга "еш һәм күп тапкырлар кайту" мәгънәсендәге фигыльдән ясалган, ягъни Аллаһыга тәвәккәл кылып, Аннан гафу сорау мәгънәсендә.

Ахшам намазының ике рәкәгать сөннәте әүвәбин намазының алты рәкәгатенә керүе хакында хәнәфи мәзһәбе галимнәре арасында каршылыклар бар. Имам Шурунбуләли "Мараки әл-Фәлак" хезмәтендә болай дип яза: "Ахшамнан соңгы алты рәкәгатькә ахшамның ике рәкәгате керми".

Бу фикер буенча, башта ахшамның ике рәкәгать сөннәте, аннары алты рәкәгать әүвәбин намазы укылырга тиеш.

Башка фикер дә бар дидек. "Әд-Дурр әл-Мохтар" хезмәте авторы болай дип әйтә: "Ике рәкәгать сөннәт муәккадә алты рәкәгать мөстәхәб өлеше саналамы? Аларны бер сәлам белән укырга ярыймы? Әл-Камәл (Ибне Хөмәм) "Әйе" дигән фикердә".

Димәк, әгәр иң элек ахшам намазының ике рәкәгать муәккадә сөннәтен, аннары алты рәкәгать әүвәбин намазын уку хәерлерәк. Башка фикерләр дә барын исәпкә алып, дүрт рәкәгать әүвәбин намазын уку да ярый.

Ә Аллаһы – яхшырак Белүче.

## Намаздагы сүрәләрнең озынлыгы хакында

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Намазның беренче рәкәгатендә кыска сүрә, ә икенчесендә озын сүрә укысаң, намаз дөрес буламы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Намазның икенче рәкәгатендә "Фәтиха" сүрәсеннән соң беренче рәкәгатьнекенә караганда кыскарак сүрәләр уку хәерлерәк.

"Әл-Фәтәва әл-Хиндия" авторы болай дип яза:

"Коръәнне беренче рәкәгатьтә икенчесенә караганда озынрак уку барлык галимнәр тарафыннан иртәнге намазның сөннәте дип санала. Имам Мөхәммәд рахимәһуллаһи: "Мин барлык намазларда да беренче рәкәгатьтә озынрак сүрә уку хәерле дип саныйм", – дип әйткән. Фәтва шушы фикердән чыгып бирелгән".

Намазның беренче рәкәгатендә икенчесенә караганда 3 аять яисә аннан күпкә кыскарак сүрә уку мәкруһ тәнзиһән хөкемендә. Әмма намаз дөрес була.

Имам Әл-Хәскафи исә "Дурр әл-мохтар" хезмәтендә болай яза:

"Икенче рәкәгатьне беренчесенә караганда озынрак уку – мәкруһ."

Шунлыктан, икенче рәкәгатьтә укыган сүрәләрнең беренчесеннән кыскарак яисә шул аятьләрнең зурлыгына тигез булуы хәерлерәк.

Ә Аллаһыга яхшырак Белүче.

## Тәсбих: фарыз яки сөннәт намаздан соңмы?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Берничә ел түбәндәге хәлне күзәтәм. Кайбер мөселман кардәшләребез фарыз намаздан соң ук тәсбих әйтергә тотына, гәрчә имам һәм мәчеткә йөрүче калган кешеләр тәсбихне сөннәт намаздан соң әйтсә дә. Элек бу хәлгә игътибар бирмәскә тырыштым. Алар башка мәзһәбкә иярүчеләр булырга мөмкин дип уйладым. Әмма, бервакыт, аларның берсе актив агитация алып бара башлады, имештер, имам дөрес эшләми, бу – бидгать дип белдерде. Һәм алар кебек эшләргә – ягъни фарыз намаздан соң тәсбих әйтергә кирәк диде. Мин бөтенләй буталып беттем. Зинһар өчен, бу мәсьәләгә ачыклык кертергә ярдәм итсәгез иде. Рәхмәт.**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

Әйе, дөрестән дә, кызганыч ки, әмма мондый күренешләр булырга мөмкин. Гыйлем җитмәү һәм күп нәрсәләрне дөрес аңламау сәбәпле, кайбер кешеләр дини сорауларны үзләренчә аңлатырга тотына. Алай гына да түгел, алар өммәттә танылу алган чын галимнәр тапшырган белемнәрне кире кагып, абсолют хакыйкатькә дәгъва кыла башлый.

Әлеге сорауга җавап бирү өчен, сезне иң әүвәл галимнәребезнең методологиясе белән таныштырырга телибез. Аннары мөһим нәтиҗәләр чыгару мөмкин булачак.

Әлегә теманы тикшереп, имам Ибне Габидин рахимәһуллаһи:"Сөннәт намазын"Аллаһүммә..." сүзләрен әйтер өчен, таләп ителгән вакыт аралыгына калдырып торыла", – дип әйткән. Аның дәлиле Гайшә радыяллаһу ганһәдән тапшырылган хәдискә нигезләнә. Әлеге хәдис Мөслим һәм Тирмизи җыентыкларында урын алган. Бу хакта Гайшә радыяллаһу ганһә түбәндәгеләрне әйткән: «Аллаһының Илчесе (сөннәт алдыннан фарыз намазны үтәгәннән соң) әлеге доганы ("Аллаһүммә әнтәс-сәләмү вә минкәс-сәлам табәрактә йә зәл-җәләли вәл-икрам") укыр өчен кирәк булган вакыттан да күбрәккә утырмаган.

Тәсбих фарыз намаздан соң кылыну турында хәбәр ителгән хәдисләргә килгәндә, бу гамәлнең сөннәтне үтәр алдыннан эшләнүе әйтелми. Мондый хәдисләрдән аңлашылган дөрес мәгънә шулдыр ки: тәсбих сөннәт намазны үтәгәннән соң башкарылган, чөнки сөннәт турыдан-туры фарыз намаз белән бәйле булып тора һәм аны тулыландыра. Сөннәт шулай ук фарыз намаздан аерым булып тормый. Шул сәбәпле, сөннәттән соң башкарыла торган барлык гамәлләр фарыздан соң килүче гамәл булып тора. Моннан тыш, Гайшә радыяллаһу ганһә вакыт аралыгын да искә ала. Димәк, әлеге хәдистән Пәйгамбәребез галәйһиссәлам (һәрвакыт) нәкъ менә шул сүзләрне әйтүе хакында белдерелми. Мөгаен, бу хәдис Пәйгамбәр галәйһиссәлам (фарыз намазны үтәгәннән соң) әлеге сүзләрне әйтү өчен җитәрлек булган вакыт аралыгына игътибар юнәлтәдер. Шулай итеп, ул Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең һәрбер фарыз намазны үтәгәннән соң түбәндәге сүзләрне әйтүе хакындагы сахих хәдисләрнең ике җыентыгында килгән мәгълүматка берничек тә каршы килми:

لا  إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ، اللَّهُمَّ لَا مَانِعَ لِمَا أَعْطَيْت وَلَا مُعْطِيَ لِمَا مَنَعْت وَلَا يَنْفَعُ ذَا الْجَدِّ مِنْك الْجَدُّ

Имам Зәфар Әхмәд Усмани рахимәһуллаһиның «Игълә Әссүнән» дип аталган хезмәттә әйткән сүзләреннән аңлашылганча, Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең һәр намаздан соң зикернең кайсы да булса бер төрен әйтүе ачык булып тора (алар хакында без югарыда сүз алып барган идек). Тапшыручыларның һәрберсе аңа ишетү насыйп булган зикер төре турында хәбәр иткән. Пәйгамбәр галәйһиссәламнең һәрбер намаздан соң төрле хәдисләрдә телгә алынган барлык төр зикерләрне әйтеп чыгу ихтималлыгы – бик аз. Әлеге факт һичьюгы аз гына булса да аңларга теләге булган теләсә кем өчен ачык. Гайшә радыяллаһу ганһәдән килгән хәдистән аңлашыла торган мәгънә фарызны укыганнан соң сөннәтләре үтәлә торган намазларга күрсәтә (биредә фарызны укыганнан соң Пәйгамбәр галәйһиссәлам сәлам догасын уку өчен кирәк булган вакыттан да күбрәк утырып тормыйча, сөннәтне үтәргә керешкән). Ә намаздан соң озак зикер кылу хәбәр ителә торган хәдисләрдә фарыздан соң сөннәтләр укылмый торган намазлар турында әйтелә, әгәр фарыздан соң сөннәт булса, зикер сөннәттән соң әйтелә. Шулай итеп, барлык хәдисләр дә, берләштергәннән соң, бер мәгънәгә күрсәтәләр. Фикер каршылыкларының асылы шунда ки: сөннәт намаз турыдан-туры фарыз намазга бәйләнгән, ул фарыз намаз белән бергәлектә башкарыла, бәйлелек бар, сөннәтне үтәүгә ашыгу кирәклеге раслана. Димәк, мондый тәҗрибә (ягъни күрсәтелгән тема буенча барлык хәдисләрне куллану тәҗрибәсе) иң дөресе булачак, бу хакта без югарыда әйтеп уздык.

**Нәтиҗә:**

1. Нинди дә булса дини-хокукый мәсьәләне караганда, хәнәфи мәзһәбе нигезендә, аерым хәдисләрне генә түгел, ә Аллаһының Илчесе галәйһиссәламгә барып тоташкан барлык мәгълүматны да исәпкә алырга кирәк. Юкса, безнең хөкем (хокукый норма) эшләрнең чын торышын чагылдырмаячак.

2. Югарыда китерелгән хәдисләрдән аңлашылганча, фарыздан соң сөннәте булмаган намазларда, тәсбих фарыздан соң кылына. Ягъни, иртәнге һәм икенде намазларыннан соң тәсбих фарыздан соң ук, имам "сәлам" догасын укыгач ук кылына. Ә фарыздан соң сөннәтләр укыла торган намазларда, без, фарыз намазны укыганнан соң, "сәлам" догасын укыйбыз, сөннәт намазны башкарабыз, ә аннары тәсбих әйтәбез. Мондыйларга өйлә, ахшам һәм ястү намазлары керә.

3. "Сәлам" догасы урынына төрле хәдисләрдә китерелгән кайсы доганы укысаң да була.

Ә Аллаһы яхшырак Белүче.

■ **Булат Мөбарәков,**
**ТҖ МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе**

# Ураза гаете көнендә Татарстан мөфтие Республика Президенты белән очрашты

24 нче май көнне Рамазан ае төгәлләнү һәм ураза тәмамлану уңаеннан үткәрелгән Ураза бәйрәме көнендә, Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов республика мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин белән очрашты.



Очрашу башында ук җитәкчеләр бәйрәм уңаеннан бер-берсен котлады. Аерым алганда, Рөстәм Нургали улы түбәндәгеләрне билгеләп үтте:

– Республика мөселманнарына, православие дине һәм башка традицион диннәр вәкилләре белән берргәттән, Раббыбыз һәм җәмгыятебез алдындагы зур җаваплылыкны тулысынча аңлаулары, кешелеклелек һәм күркәм күршелек идеалларына тугры калулары өчен рәхмәт сүзләремне җиткерәм.

Ул шулай ук мөселманнарның мохтаҗ, ялгыз һәм авыру кешеләргә, өлкәннәргә һәм күпбалалы гаиләләргә рухи һәм матди булышлык күрсәтүен, зур социаль әһәмияткә ия булган иҗтимагый башлангычлар кысаларында ифтар ризыклары җыелмаларын хәстәрләүдә шәхсән катнашуын ассызыклады.

Мөфти хәзрәт, үз чиратында, Президентка Ураза бәйрәме уңаеннан бүләк тапшырды һәм туры эфирда "Галиев" мәчетендә укылган бәйрәм вәгазе турындагы тәэсирләре белән уртаклашты. Камил хәзрәт белән Рөстәм Нургали улының очрашулары телевизион яңалыклар белән бер вакытка туры килде – сюжетларда Рәсәйнең төрле регионнарында Гает уздыру турында сөйләнде һәм иң беренче үрнәк итеп Татарстан күрсәтелде. Бу уңайдан җитәкчеләр республикада узган Рамазан ае, Ураза бәйрәме, мөфтинең туры эфирда вәгазь сөйләве турында фикер алыштылар. Үзенең вәгазендә Камил хәзрәт дин кардәшләрнең игътибарын Рамазан ае һәм Ураза гаетенең фазыйләтләренә юнәлтеп кенә калмыйча, шулай ук Аллаһының насыйбы белән бөтен кешелек дөньясын камап алган пандемиянең сәбәпләре турында да уйларга өндәде. Бәйрәм вәгазенең турыдан-туры трансляциясе телевизион һәм онлайн рәвештә оештырылды.

Алга таба очрашу барышында Камил хәзрәт Рөстәм Нургали улына узган Рамазан аеның нәтиҗәләрен җиткерде:

"Рамазан аеның җөмһүриятебездә, илдә һәм дөньяда барган катлаулы санитар-эпидемиологик вәзгыятькә туры килүенә дә карамастан, Татарстан өммәте өчен ураза аеның 30 көне дә нәтиҗәле узды. Мәчетләргә йөрүне һәм массакүләм чараларны тыю Рамазанның шатлыгын сүрелдерсә дә, аның каравы, мохтаҗларга ярдәм итүдә дин кардәшләребез зур теләктәшлек һәм күркәм үрнәк күрсәтте".

Мөфти сүзләренә караганда, быел "Рамазан – изге гамәлләр ае" хәйрия марафоны әлегә кадәр күрелмәгән зур колач белән узды. Әлеге акция кысаларында җыелган акчалар 10 авыру балага дәваланыр өчен түләргә, 180 мең аз керемле кешегә азык-төлек ярдәме күрсәтергә, Ютазы районы Иске Каразирек авылында үзүзенңе читләштерү режимы вакытында янган мәчетне торгызу өчен ярдәм итүгә тотылды.

Ел саен рекордлар куя торган Республикакүләм ифтар быел да яңа үрләргә иреште һәм Рамазан аеның истә калырлык олы вакыйгасы булды: аның кысаларында Татарстанның 40 районына һәм Казанның 60 мәчетенә 30 мең мохтаҗ кешегә тарату өчен ифтар җыелмалары тапшырылды, 500дән артык ихтыярчы җәлеп ителде. «Ярдәм» мәчете тарафыннан тормышка ашырылган «Дорога жизни» акциясе шулай ук зур масштабта үткәрелеп 60 мең мохтаҗ кешене ифтар җыелмалары белән тәэмин итте. Пандемия шартларында барлык хәйрия чаралары да санитар нормаларны үтәп гамәлгә ашырылды. Мөселманнарга уңайлы булсын өчен, ТҖ мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды тарафыннан фитыр, фидия, зәкят һәм садака акчаларын читтән торып җыю оештырылды.

Пандемия шартларында Рамазан аен һәм Ураза бәйрәмен үткәрү тәртибе Татарстанның мөселман җәмәгатьчелегендә бик күп сораулар тудырды. Халык арасында аңлату эшләре алып бару өчен, ТҖ мөселманнары Диния нәзарәтенең "Даруль ифта" call-үзәге эшчәнлеген көчәйтелгән режимда алып барды. Рамазан аеның беренче көнендә генә дә мәчетләрнең эшләү тәртипләре, ураза тоту, намаз вакытлары үзгәрү һәм башка мәсьәләләр буенча йөздән артык мөселман мөрәҗәгать итте. Рамазан ае барышында шәригать белгечләре 1500дән артык шалтырату һәм мөрәҗәгатьне эшкәртте.

Аңлашыла ки, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең барлык дәгъват һәм яшьләр проектлары шулай ук онлайн режимга күчерелән иде: үз-үзеңне читләштерү режимы чорында һәм Рамазан аеның 30 көнендә мөфтият тарафыннан 94 онлайн-лекция, туры эфир, вәгазь үткәрелде. Уртача алганда, бу дәресләрдә 400ләп кеше катнашты. Лекцияләр ZOOM платформасында һәм Инстаграм социаль челтәренең турыдан-туры эфирында @muslimmol, @islam_today_huzur, @huzurmedia h.б. укылды.

Рамазан аеның бизәге булып шулай ук Коръән хәтем кылу – Изге Китапны тулысынча укып чыгу торды. Ул уразаның беренче көнендә Казан шәһәренең "Галиев" мәчетендә башланып китте һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте сайты аша көн саен туры эфирда трансляцияләнде. Хәтем кылу Рамазан аеның соңгы көнендә – 23 нче майда төгәлләнде. Соңгы 30 нчы җөзне Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин укыды.

Моннан тыш, Татарстан Президенты белән әңгәмә вакытында ТҖ мөселманнары Диния нәзарәте башлыгы мөфтият эшчәнлегенең соңгы 12 айдагы төп нәтиҗәләре белән таныштырды. Ул ассызыклап узганча, ТҖ мөселманнары Диния нәзарәте Тәфсир елы кысаларында Кәлам Шәриф мәгънәләренең татар һәм рус телләренә тәрҗемәләрен бастырып чыгарды һәм аны татар җәмәгатьчелегe өчен Мәскәүдә, шулай ук Махачкалада уңышлы рәвештә тәкъдим итте. Агымдагы ел Татарстанда мөфтият тарафыннан Туган тел елы дип игълан ителде. Шулай итеп, 2020 елда мөфтият һәм аңа караган оешмалар үз эшчәнлекләрен мәчетләрдә татар телле мохитне үстерү, татар телен өйрәтү, татар рухи мирасын популярлаштыру, халыкта милли үзаңны тәрбияләү, милли үзенчәлекләрне саклап калу кебек максатларны исәпкә алып башкарачак.

Камил хәзрәт Татарстанның 20 мәчетендә оештырылган татар теле курслары нәтиҗәләренә аерым тукталды. Аның кысаларында татар теленең башлангыч дәрәҗәсен быел 436 тыңлаучы уңышлы үзләштерде. Мөфти хәзрәт шулай ук татар теле курсларының географиясен киңәйтү, "Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә" басмасының яңартылган редакциясен татар халкы күпләп яшәгән төбәкләргә алып чыгып тәкъдим итү, милли һәм дини үзенчәлекләрне саклау буенча очрашулар үткәрү планнары белән уртаклашты.

# Кеше – иң мәртәбәле зат



## Озак көтеп алынган кунак

**“Без кешене иң күркәм сурәттә яраттык”.**

«Тин / Инҗир», 95:4

**“Кешене Без яраттык һәм нәфесенең аңа нәрсәләр пышылдаганын беләбез. Без (гыйлемебез белән) аңа муен тамырларыннан да якынрак”.**

«Каф», 50:16

Безнең Җир йөзе көтеп алынган кунакны – кешене кабул итәргә озак әзерләнгән. Җир шары үз күчәре тирәсендә һәм Кояш тирәли үз орбитасында хәрәкәт иткән.

Һәм аның хәрәкәт итүе, күчәр тирәсендә әйләнү ярдәмендә, көнне төнгә, төнне көнгә алмаштырган. Ә Кояш тирәли хәрәкәт итү ярдәмендә ел фасыллары алышынган.

Кояшка кадәр ара төгәллек белән үлчәнгән. Әгәр дә ул әз генә кимрәк булса, Җир йөзендәге бөтен әйбер янып бетеп көлгә әйләнер, әгәр инде бераз гына күбрәк булса, Җир йөзен боз каплар иде.

**“Ул күкләр белән җирне һәм алар арасындагыларны алты көндә яратты, шуннан соң (ниндидер бер урынга урнашудан пакь булуларак, Затына килешкән шәкелдә) Гарешкә истива кылды. Ул җир эченә кергән нәрсәләрне дә, аннан чыккан (үсемлекләр, чишмәләр кебек) нәрсәләрне дә, күктән иңгән (яңгыр, китаплар, тәкъдирләр кебек) нәрсәләрне дә һәм аңа күтәрелгән (томаннар, фәреш-тәләр, догалар кебек) нәрсәләрне дә белә. Кайда гына булсагыз да, (гомуми мәгънәдә – гыйлеме һәм кодрәте белән, хосусый мәгънәдә – Үзенең рәхмәте белән) Ул сезнең белән бергә. Аллаһы сезнең ни кылганнарыгызны күрә”.**

«Әл-Хәдид / Тимер», 57:4

Җирне әйләндереп алган атмосфера төрле тышкы йогынтыларга каршы торыр өчен кирәк булган.

Бөтен әйбер дә көтеп алынган кунак өчен сыеныр урын булырлык итеп барлыкка китерелгән. Җир йөзе шулхәтле матур итеп яратылган ки, хәтта Аллаһыдан кала берәүнең дә бу матурлыкны тасвирларга көченнән килмәс иде.

Бөтен нәрсә, һәр нечкәлеге белән, күптән көтеп алынган кунак өчен әзерләнгән, һичнәрсә күз уңыннан читтә калмаган.

Бар нәрсә дә әзер булгач, ниһаять билгеләнгән вакыт килеп җиткән, адәм баласы яратылып, бу матур урынга җибәрелгән.

Әлеге гаҗәеп зат башка затларга охшамаган, ул акылга һәм сайлау хокукына, үзенең хис-кичерешләренә, фикер йөртүенә һәм сөйләмгә ия булган.

## Безнең өчен һәркөнне кояш чыга

Галәмнең бер генә Хуҗасы бар. Ул – Аллаһы Тәгалә. Аллаһы бернәрсә дә булмаганда да бар иде. Аллаһы Галәмне, планеталарны, йолдызларны, айны, кояшны бар кылган, Җир йөзендәге һәрнәрсәгә тормыш биргән, бар нәрсәне билгеләп куйган.

Аллаһы бу Җир йөзен безнең өчен яратты. Аннары анда таулар, тигезлекләр, диңгезләр һәм елгалар урнаштырды, җилне, туфракны, суны һәм һаваны булдырды; табигатьне якты нурлар, төрле төсләр, тавышлар белән бизәде; безнең өчен барлык тереклекне, үләннәрне, кошларны, бөҗәкләрне, чәчәкләрне халик кылды. Ул урманнарны, җимеш бирә һәм бирми торган агачларны бар кылды, төрле төстәге һәм шәкелдәге чәчәкләрне хасил итте, якты яшел төстәге үрмәле гөлләрне, мәңге яшел агачларны яратты. Аллаһы кечкенә кырмыскадан башлап, зур филләргә хәтле – барлык хайваннарны да халик кылды. Аллаһы Тәгалә аларның кайберләрен аяксыз, кайберләрен дүрт аяклы, ә кайберләрен күп аяклы итеп барлыкка китерде; кошларны очар өчен канатлар, ә балыкларны йөзәр өчен йөзгечләр белән тәэмин итте. Ул бал кортларына бал ясауны өйрәтте һәм Җир йөзенә кирәк булган һәммә әйберне дә барлыкка китерде.

**“Һичшиксез, күкләрнең һәм җирнең яратылышында, төн белән көннең бер-бер артлы килүендә, кешеләргә файдалы (азык-төлек, кием-салым һәм ягулык кебек) нәрсәләр белән (йөкләнеп) диңгездә йөргән көймәләрдә, Аллаһы күктән яудырган суда һәм (шул сулары белән) үлгәненнән соң җирне терелтүендә, анда хәрәкәт итә алган төрле хайваннар таратуында, җилләрнең (бер яктан бер якка) үзгәрүендә һәм җир белән күк арасында (Аллаһының яудыру әмеренә) буйсындырылган болытларда, (акыл күзе белән карап яхшылап төшенеп, хакыйкатьне) аңлый алган кешеләр өчен, әлбәттә, билгеләр бар”.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:164

Җир йөзендәге бөтен әйбер дә Аның “Бул!” дигән сүзе белән барлыкка китерелде.

Һәркөнне безнең өчен кояш чыга, безнең өчен елгалар ага, һәр яз фасылында табигать аллы-гөлле чәчәкләргә, моңлы кош авазларына күмелә. Аллаһы безне бик нык ярата. Без никадәр генә Аңа рәхмәтләребезне белдерергә тырышсак та, моны тулысынча булдыра алмаячакбыз, чөнки аның безгә биргән нигъмәтләре чиксез.

Бик күп төрле үләннәр, хайваннар, чәчәкләр, җиләк-җимешләр бар. Аларның һәрберсенең үз матурлыгы, үз үзенчәлеге. Әгәр уйланып карасак, бу матурлыкны халик кыла алмаячагыбызны аңларбыз. Шул таң калырлык Җир йөзендә гаҗәеп адәм баласы яши. Бу матур дөнья тагын да матуррак зат – Кеше өчен хезмәт итә. Раббыбыз кешене иң югары дәрәҗәләргә күтәреп, бу матурлыклардан да өстен итеп барлыкка китергән.

Без адәм баласын юктан бар кылган, аңа куллар, аяклар, күзләр, колаклар биргән, эти белән әниле иткән Раббыбызга ышанабыз. Ул бар һәм Ул Берәү генә. Раббыбыз бар әйберне дә бер Үзе генә барлыкка китерде, моны эшләү өчен Аңа берәүнең дә ярдәме кирәк булмады. Аллаһы тумады, берәүне дә тудырмады, Аның баласы юк һәм Ул балага мохтаҗ түгел.

Без Расүлебез галәйһиссәламнән, Изге Коръәни Кәрим китабыбыздан бердәнбер булган Аллаһының барлыгын, Аның ярдәмчеләре булмавын һәм бу Галәмнәрнең Яратучысы булуын беләбез.

■ **Сәхифәне Айсылу Юлдашева әзерләде**

# Теләк (хаҗәт) намазы догасы

Бу хөрмәтле Пәйгамбәр галәйһисsәламнең өйрәткән догаларының берсе:

لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ الْحَلِيمُ الْكَرِيمُ. سُبْحَانَ اللهِ رَبِّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ. الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ أَسْأَلُكَ مُوجِبَاتِ رَحْمَتِكَ وَعَزَائِمَ مَغْفِرَتِكَ وَالْغَنِيمَةَ مِنْ كُلِّ بِرٍّ وَالسَّلَامَةَ مِنْ كُلِّ إِثْمٍ. لَا تَدَعْ لِي ذَنْبًا إِلَّا غَفَرْتَهُ وَلَا هَمًّا إِلَّا فَرَّجْتَهُ وَلَا حَاجَةً.هِيَ لَكَ رِضًا إِلَّا قَضَيْتَهَا يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

«Ләә иләһә илләллааһүл-хәлиимүл-кәриим. Сүбехәәнәллааһи раббил-гәршил гәзыйм. Әлхәмдү лилләәһи раббил-гааләмиин, әс-әлүкә мүҗибәәти рахмәтикә вә газәә'имә мәгъфиратикә вәль-ганиимәтә мин күлли биррин вәс-сәләәмәтә мин күлли исм. Ләә тәдәгь лии зәнбән илләә гафәртәһү вә ләә һәммә илләә фәрраҗтәһү вә ләә хәәҗәһ. Һийә ләкә ридан илләә кадайтәһәә йәә әрхәмәр-раахимиин».

«Хәлим һәм юмарт булган Аллаһыдан башка һичбер илаһ юк. Бөек Гарешнең Раббысы булган Аллаһының кимчелекләре юк. Мактау галәмнәрнең раббысы Аллаһыга хас. Синнән, рәхмәтең белән яхшылык бирүең аркасында яхшылык сорыйм. Янә дә һәр яктан гафу итүеңне һәм гөнаһтан саклавыңны сорыйм. Миндә гафу ителмәгән бер генә гөнаһымны, бетерелмәгән бер генә борчуымны да калдырма. Әй мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе! Үзең риза булган теләгемне үтә».

# Ачу чыкканда укыла торган догалар

Пәйгамбәребез ачуы чыккан кешегә тәһарәт алуны, басып торса утыруны, утырса ятуны киңәш иткән, ә тагын бер хәдисендә болай дип әйтергә кушкан:

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ.

«Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим».

«Аллаһының рәхмәтеннән мәңгегә куылган шайтанның начарлыгыннан Аллаһыга сыенам».

Сөләйман бине Сард болай дигән: «Аллаһының Расүле белән утыра идек. Ике кешенең бер-берсен сүккәнен ишеттек. Берсенең йөзе кызарган. Аллаһы Расүле: «Мин бер сүз беләм, аны әйткән булса, бу хәл үзеннән-үзе бетәр иде. Ул: «Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанирраҗииим», – дип әйтте.

Тагы Пәйгамбәребез бу доганы өйрәткән:

اللَّهُمَّ اغْفِرْ ذَنْبِي وَأَذْهِبْ غَيْظَ قَلْبِي وَأَجِرْنِي مِنَ الشَّيْطَانِ.

«Аллааһуммә-гъфир зәмбии вә-әзһиб гайзә кальбии вә әҗирнии минәш-шәйтааан».

# Күз тимәсен өчен укыла торган дога

Пәйгамбәребез Хәсән белән Хөсәенгә күз тимәсен дип мондый дога кылган:

أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللهِ التَّامَّةِ مِنْ كُلِّ شَيْطَانٍ وَهَامَّةٍ وَمِنْ كُلِّ عَيْنٍ لَامَّةٍ.

«Әгүүзү бикәлимәәтилләәһиттәәммәти мин күлли шәйтаанин вә һәәммәтин вә мин күлли гайнин ләәммәһ».

«Һәр шайтаннан, зарарлы әйберләрдән һәм начар күзләрдән Аллаһыга сыенам».


Күз тиюдән бу аятьне уку киңәш ителә:

وَإِن يَكَادُ الَّذِينَ كَفَرُوا لَيُزْلِقُونَكَ بِأَبْصَارِهِمْ لَمَّا سَمِعُوا الذِّكْرَ وَيَقُولُونَ إِنَّهُ لَمَجْنُونٌ ﴿٥١﴾ وَمَا هُوَ إِلَّا ذِكْرٌ لِّلْعَالَمِينَ ﴿٥٢﴾

«Вә ий-йәкәәдүлләзиинә кәфәруу ләйүзликуунәкә биәбсаарииһим ләммәә сәмигүз-зикра вә йәкуулүүнә иннәһүү ләмәҗнүүн. Вә мәә һүә илләә зикруль лилгааләмииин».

Каләм, 68:51-52

**«Чынлап та, шул имансызларның, Коръәнне ишеткән вакытта, сине күзләре белән бәреп егасы килә иде. «Ул, һичшиксез, акылдан язган кеше», – дияләр. Ә Коръән бөтен галәмнәр өчен шәфкатьтән башка бер әйбер дә түгелдер».**



# Истихара догасы

اَللَّهُمَّ إِنِّي أَسْتَخِيرُكَ بِعِلْمِكَ وَاسْتَقْدِرُكَ بِقُدْرَتِكَ وَأَسْئَلُكَ مِنْ فَضْلِكَ الْعَظِمِ فَإِنَّكَ تَقْدِرُ وَلَا أَقْدِرُ وَتَعْلَمُ وَلَا أَعْلَمُ وَأَنْتَ عَلَّامُ الْغُيُوبِ. اللَّهُمَّ إِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الْأَمْرَ خَيْرٌ لِي فِي دِينِي وَمَعَاشِي وَعَاقِبَةِ أَمْرِي فَاقْدِرْهُ لِي وَيَسِّرْهُ لِي ثُمَّ بَارِكْ لِي فِيهِ. وَإِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الْأَمْرَ شَرٌّ لِي فِي دِينِي وَمَعَاشِي وَعَاقِبَةِ أَمْرِي فَاصْرِفْهُ عَلَى وَاصْرِفْنِي عَنْهُ وَاقْدِرْ لِي الْخَيْرَ أَيْنَمَا كُنْتُ. إِنَّكَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ.

«Аллааһуммә инниии әстәхыйрукә бигыйльмикә вә әстәкдирукә бикудратикә вә әс'әлүкә мин фадликәл-газыйми. Фәиннәкә тәкъдиру вә ләә әкъдиру вә тәгъләмү вә ләә әгъләмү вә әнтә галләәмүл-гуйүүб. Аллааһуммә ин күнтә тәгъләмү әннә һәәзәәл-әмра хайрун лии фии диинии үә мәгаашии үә гаакибәти әмрии фәкъдирһү лии вә йәссирһү лии сүммә бәәрик лии фииһ. Үә ин күнтә тәгъләмү әннә һәәзәәл-әмра шәррун лии фии диинии үә мәгаашии вә гаакыйбәти әмрии фәсрифһү галәә вәсрифнии гәнһү вәкъдир лил-хайра әйнәмәә күнт. Иннәкә галәә күлли шәй'ин кадиир».

«Йә Рабби, дөреслектә, мин Синнән Үз гыйлемең белән ярдәм итүеңне, кодрәтең белән миңа көч бирүеңне һәм Синең олуг рәхмәтеңне сорыйм. Дөреслектә, Синең кодрәтең бар нәрсәгә җитә, мин үзем генә (Синең кодрәтең булмаса) һичбер нәрсә эшли алмыйм. Син һәрнәрсәне беләсең, ә мин белмим. Дөреслектә, Син һәрбер яшерен нәрсәләрне беләсең. Йә Аллаһы, әгәр бу эшемне динем, дөньям һәм Ахирәтем өчен хәерле дип белсәң, аны миңа насыйп ит һәм ул эшне минем өчен мөбарәк кыл. Әгәр дә бу эшемне динем, дөньям һәм Ахирәтем өчен зарарлы һәм яман дип белсәң, ул эшне миннән һәм мине ул эштән азат ит. Кайда булсам да, миңа хәерле эшләрне насыйп ит. Дөреслектә, Синең көчең һәрнәрсәгә җитә».

Моннан соң дога кылган кеше теләген әйтер.

# Күк күкрәгәндә, яшен яшьнәгәндә укылачак дога


Бу доганы укырга Пәйгамбәребез киңәш иткән:

اللَّهُمَّ لَا تَقْتُلْنَا بِغَضَبِكَ وَلَا تُهْلِكْنَا بِعَذَابِكَ وَعَافِنَا قَبْلَ ذَلِكَ.

«Аллааһуммә ләә тәкътүлнәә бигадабикә вә ләә түһликнәә би газәәбикә вә гаафинәә каблә зәәлик».

«Аллаһым! Ачуың белән үтермә, ачуың белән дә безне һәлак итмә. Моннан соң булачак начар нәтиҗәләрдән безне сакла».

# Ни өчен Казахстанда татарлар күп яши?



Казахстанда беренче таш йортны татарлар төзегәнен белә идегезме? Ә Яушевлар династиясенең икътисадка гына түгел, ә үзләренең яңа ватаннарының мәдәни үсешенә дә йогынты ясаганын?

Ә казакъ җирлегендәге татар мәчетләренең үзенчәлекләрен беләсезме? Ә татарларның Казахстан территориясенә ничек эләгүе турында уйлап караганыгыз бармы? Белмисезме, алайса без сезгә татар халкы һәм аның туган республикабыз гына түгел, дөньяның башка илләре тормышында тоткан роле турында сөйләүне дәвам итәбез.

Тарихи риваятьләргә карасак, татарлар Казахстан җирләренә XVII йөз азагында күченә башлыйлар. Әмма тирәнрәк казып карасак, татарларның Даладагы (Казахстанда) тарихы, Алтын Урда оешканчы ук, X-XIII гасырларда ук башланган булуын белергә мөмкин. Һәм шушы озак еллар бергә яшәп, бу ике тугандаш республика халыклары якынайдылар һәм туганлаштылар.

### Татарлар һәм Дала

Нәкъ менә татарлар төркиләрдән беренчеләрдән булып утрак тормышка күчтеләр. Безгә килеп җиткән тарихи язмалардан чыгып, XVII йөзнең беренче яртысында ук, Уральскида Татар бистәсе формалаша башлаганын беләбез. Анда, казакълардан тыш, игенчелек, һөнәрчелек, сәүдә белән шөгыльләнүче татарлар килеп урнашалар.

XVII йөзнең икенче яртысында Әстерхандагы татар сәүдәгәрләре 1640 елда нигезләнгән Түбән Җаек шәһәрчегенә (хәзерге Атырау шәһәре) килә башлыйлар. XVIII йөзнең беренче яртысында татарларны, казакъ ханнарының язып баручы һәм тәрҗемәчеләре буларак, Даланың башка төбәкләрендә дә күреп була.

### XVIII гасырда Казахстанда татарлар барлыкка килү нәрсә белән аңлатыла соң?

Тикшеренүчеләр моның сәбәпләре күп дип сөйли, ләкин беренче чиратта, 1731 елда Кече һәм Урта жүчиненң Россия империясенә кушылуы турында искә алырга кирәк. Шул вакыттан алып татарларның Казахстан җирендә яшәүчеләргә тормышның барлык өлкәләрендә дә: икътисадтан башлап, мәдәнияткә һәм мәгарифкә кадәр йогынтысы арту хисабын алып барырга мөмкин. Мәсәлән, татар халкы яшәү урыннарында беренче татар мәктәпләре, рәсми рәвештә күпкә соңрак теркәлгән булуларына карамастан, XVIII гасырда ук барлыкка килә.

XIX гасыр ахырында татар мәдрәсәләре Казахстанның барлык эре шәһәрләрендә һәм татар торак пунктларында диярлек эшләп килгән. Татар мәктәпләрендә татарлар гына түгел, казахлар да күпләп укый. Бу эштә ике халыкның телләре якынлыгы да, шулай ук татар халкының югары дәрәҗәдә белемле булуы да, җирле халыкка булган белемнәрне җиткерергә ашкыну да ярдәм итте.

Семипалатинскта, 60 нчы еллардан алып, XVIII йөзнең 90 нчы елларына кадәр, эшкуар татарлар Полковничье ярымутравындагы Меновой бистәсе территориясендә урнаша. Иртышның көчле ташкыннары аркасында 1798 елда бистә яңа урынга күчерелә, соңрак ул Татар бистәсе дип атала башлый, анда сәүдәгәрләр кунакханәләр һәм Казахстандагы Татар бистәсенең мәҗбүри атрибуты булган мәчетләр төзегәннәр . Тиздән бу бистә шәһәрдә иң зур бистәләрнең берсе булачак һәм нигездә рус халкы яшәгән крепость форштадты белән көрәшәчәк.

XVIII-XIX гасырларда татарлар казах даласының бөтен территориясендә диярлек тарала. Аларның гомуми саны 50 меңнән артык кешегә җиткән.

### Татарлар һәм казахлар – ике тугандаш халык


Халыкның үз вакытлы матбугатыннан башка яшәвен күз алдына да китереп булмый. Безнең очракта да шулай булды. Нәшриятның югары ноктасы революция һәм революциядән соң чорга туры килде. XX гасыр башында казах даласында мөселманнар арасында театр хәрәкәте дә популярлаша башлый. Башта анда Казаннан килгән “Сәйяр”, “Нур”, “Ширкәт” труппалары гастрольләрдә булган, алар еш кына җирле татарларны зур булмаган рольләргә җәлеп иткәннәр, соңыннан алар Акмолинск, Петропавловск, Верный, Кустанай һәм Семипалатинск кебек шәһәрләрдә театр труппалары төзү инициаторлары булганнар.

Татар һәм казах халыкларының багланышлары турында сөйләгәндә, ике тугандаш халыклар арасындагы элемтәләрне ныгытуга, мәгърифәтчелек эшчәнлегенә бар көчләрен керткән кешеләр турында искә төшермәү мөмкин түгел. Болар – татар шагыйре Нури Арсланов (1912-1991), публицист һәм драматург Әкрам Галимов (1892-1913), тарихчы Корбангали Халиди (1846-1913), журналист һәм җырчы Камил Мотыйгый (1883-1941), рәссам Макмун Сутюшев (1906-1990) һәм башкалар.

Шәһәрләр үсеше, Урта Азия ханлыклары һәм Кытай белән сәүдә итү аша Далада татар сәүдәгәрләренең саны шактый арта. Татар сәүдәгәрләре һәм сәнәгатьчеләре шәһәр үзидарәсендә актив катнашалар һәм даими рәвештә Дала шәһәрләренең шәһәр думасына сайланалар. Татар халкының шушы үзенчәлеге белән бәйле рәвештә XIX гасырда һәм XX гасыр башында казах даласында татар буржуазиясенең көчле катламы формалашуы гаҗәп түгел. Ул тиздән социаль ярдәмгә, рухи инфраструктураны төзүгә зур өлеш кертәчәк, шулай ук шәһәрләрнең иҗтимагый тормышына сизелерлек йогынты ясаячак.

■ **Ильмира Гафиятуллина**

# Кем чыннан да җәяү йөрүче булып санала?



Берьюлы Ибраһим бине Әдһәм куддисаллаһу сирруһу җәяүләп хаҗга юл тоткан. Һәм сәфәре вакытында дөягә атланган берәүгә очраткан. Бу кеше Ибраһим бине Әдһәм хәзрәтләреннән болай дип сораган:

– Йә карт кеше! Кая юл тоттың?

– Мин Кәгъбәтуллаһка барам.

– Синең утырып барырлык хайваның юк бит. Ничек барып җитәрсең?

– Минем хәрәкәт итү чараларым бик күп.

– Нәрсәләр соң ул?

Миңа берәр бәла килсә, сабырлыкка утырам. Әгәр берәр бәхет килсә – рәхмәткә. Әгәр минем белән берәр яхшы хәл булса, мин канәгатьлелеккә утырам. Ә инде нәфесем берәр гамәлгә дәшсә, калган гомерем яшәгән гомеремә караганда азрак икәнен исемә төшереп, шул рәвешле эш итәм.

Боларны ишеткән әңгәмәдәшче:

– Син җайдак икәнсең, ә мин җәяүле. Сәфәрең имин һәм бәрәкәтле булсын, – дип әйткән.

# Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең дәрәҗәсе

Гали радыяллаһу ганһе болай дип сөйләгән: “Мин Әбү Бәкердән болай дип сорадым:

– Йә, Аллаһы Расүленең хәлифе! Син шулхәтле безне узып киттең ки, хәтта беребез дә сине куып тота алмады. Син ничек бу дәрәҗәләргә ирештең?”

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе болай дип җавап биргән:

– Мин бу дәрәҗәгә биш әйбер нәтиҗәсендә ирештем:

1. Кешеләрнең ике төркемгә бүленгәнен ачыкладым: берәүләр дөнья тормышын, икенчеләр Ахирәт тормышын тели, ә мин исә Раббыма омтылдым.

2. Мөселман булган көнемнән бирле туклanганчы ашамадым, чөнки Аллаһыны тану ләззәте дөнья нигъмәтләре ләззәтләрен каплады.

3. Мөселман булган көнемнән бирле туйганчы су да, башка эчемлекләр дә эчмәдем, чөнки Аллаһы турында белү аларны томалады.

4. Дөнья эшләре белән Ахирәт эшләрен чагыштырганда һәм араларыннан берсен сайларга кирәк булганда, Ахирәт эшләренә өстенлек бирдем.

5. Мин Аллаһы Илчесе галәйһиссәламнең дустына әйләндем һәм һәрвакыттa да бу дуслыкны иң хәерле рәвештә башкарырга тырыштым.

# Кыска гына фикер аша күпне аңлау

Бер кеше Аллаһы Илчесе галәйһиссәлам янына килеп: “Йә Расүлуллаһ! Сиңа Аллаһы өйрәткәннән миңа берәрнәрсә өйрәт әле”, – дип әйткән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер сәхабәсенә мөрәҗәгать итеп: “Бу кешегә Коръәнне өйрәтегез”, – дигән.

Сәхабәләр әлеге кешегә Зүллзиләт (Җир селкенмәк) сүрәсен өйрәтә башлаганнар. Алар сүрәнең болай дип әйтелгән соңгы аятенә килеп җиткәч **(“Кем дә кем (дөньяда) зәррә авырлыгы кадәр генә игелек кыла, аны (Ахирәттә) күрәчәк. Кем дә кем (дөньяда) зәррә авырлыгы кадәр генә начарлык кыла, аны (Ахирәттә) күрәчәк”)** бу кеше: “Булды. Миңа әлеге аятьләр җитә”, – дип әйткән.

Моның хакта Расүлебез галәйһиссәламгә хәбәр ителгәч, ул: “Әлеге кешегә карагыз! Ул диндә фикһ белгече (тирән мәгънәләрне аңларга сәләтле булучы) булды”, – дип әйткән.

■ **“Рухуль-Бәйан” китабыннан тәрҗемә**

# Белеп ышан!

Нәрсәләргә генә ышанмый адәм баласы... Йолдызнамәләргә, ырымнарга, “бу смсны җибәрсәң бәхет килә, җибәрмәсә – кайгы көт”, кебек сафсата язуларга. Хисләргә бирелмичә, бер мизгелгә генә туктапып, акыл белән уйлап караганы бармы икән кешенең?! Мәсәлән, бер көнне кысла йолдызлыгы астында туучыларны акча, байлык көтә дип язылган ди, Аллаһының рәхмәте белән берәүләр ул көнне, чыннан да, байлыкка ия була, ә шул ук йолдызлыкта туучылар, киресенчә, матди яктан кыенлык хәлендә кала. Моңы нәрсә дигән сүз?! Димәк, йолдызнамә кагыйдәсе бер төркем “кыслаларга” килешә, ә икенчеләре өчен юк? Алай булырга тиеш түгелдер бит инде. Чынлыкта, бу очраклы рәвештә бер туры килү генә, ә дөресрәге Аллаһының рәхмәте.

Ырымнарга килгәндә, анда да шул ук хәл. Күпме кеше, кара мәче юлымны бүлде, юлым уңмас инде дип, бәрәкәтле генә башланган көненә мөһер суга. Дөреслектә, урамда йөргән кара мәченең кешенең эшләре барышында бернинди дә катнашы юк. Яки, киресенчә, кеше ул көнен, кара мәче очратуына карамастан, бик уңышлы үткәрер, бу инде кара мәче очрату хәерлегә дигән сүз буламы?! Кеше юлы, эшләре уңса, иртән уңышсызлыкка китерә торган ырымнарга юлыкканын бөтенләй дә онытачак бит. Әмма инде киресенчә булса, монда үзеннән кала барысын да гаепләячәк: кара мәчене дә, йолдызнамә фаразларын да – бар нәрсәне һәм һәр кемне, тик гаепне үзеннән эзләргә генә теләмәячәк.

Ә бәлки моның сере гади генәдер: һәр кеше иртән уянуга Аллаһыга шөкерләр әйтеп, бу яңа туган көннең хәерлесен, бәрәкәтен сорарга, эшләрен уңышлы тәмамлар өчен хәләл юллар белән тырышлык куярга тиеш. Кызганычка, бу гади, әмма күпләр өчен үтәве авыр булып тоелган әлеге тәртипләрне һәркем белми, белсә дә үтәргә ашыкмый.

Кеше башын бутап, хафага сала торган смслар белән дә шул ук хәл. Психологлар кешенең баш мие һәрдаим уйлап йөргән вакыйгалар, хәлләр тормышка ашу сәләтенә ия булуын ачыклады. Ягъни без – ул безнең уйлаган фикерләребез. Шуңа да кайгы, бәла-каза килә, дигән уйларны читкә куеп, күңел дөньябызны яхшы уйлар белән генә тулыландырсак иде.

Динебезнең иман баганаларының алтынчысында Аллаһы Тәгалә яхшының да яманның да Аллаһыдан булуына ышанырга куша. Әгәр һәркем шулай эшләсә, бу аның тормышын күпкә җиңеләйтер иде, билгеле.

Бернинди кара мәчеләр дә, йолдызнамәләр дә кеше тормышына тәэсир ясый алмый. Адәм баласы боларны аңлап, үзенә кирәксез программалар көйләүдән, бу рәвешле тормышын катлауландырудан ерак булса иде.

■ **Айсылу Юлдашева**

# Шөкер итү

Шөкер итү – кешенең үз хәленнән канәгать булып, Аллаһыга рәхмәтләрен белдерүе димәктер. Шөкер итү – барлыкның Хуҗасы булган Аллаһыны олылаудыр, Аллаһыны зурлаудыр. Шөкер итү – Аллаһы Тәгалә биргән санаусыз нигъмәтләрнең кыйммәтен аңлап, аларны Аллаһы юлында куллanудыр.

Аллаһы Тәгалә кешеләргә санаусыз нигъмәтләр биргән. Ашау-эчүләребезне бар иткән, саулыкта яшәткән бөек Зат – Аллаһы Тәгаләдер. Акыл, җан, гәүдәбезгә көч-куәт биреп, төрле ниятләребезне тормышка ашырырга, төрле эшләр башкарырга мөмкинлек бирүче – Аллаһыдыр. Безнең өчен табигатьтәге һәрнәрсәне: һаваны, суны, җимешләрне, шулай ук барча хайваннарны бар итүче – Аллаһыдыр. Кеше әшрәфи мәхлукаттыр, ягъни барлыкларның иң шәрәфлесе (хөрмәтлеседер). Шулай булгач, кеше Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылырга вә бу нигъмәтләрнең чын Хуҗасын һәрвакыт олылап искә алырга тиеш.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дигән:

**«Аллаһының нигъмәтләрен санарга тотынсагыз, санап бетерә алмассыз».**

«Ибраһим», 14:34

Дөнья вә тормышыбызда кемнән булса да ярдәм күрсәк, аның нинди дә булса нигъмәтенә ирешсәк, аңа рәхмәтләр укыйбыз, ул кешегә хөрмәтебезне белдерергә тырышабыз. Үзенең санаусыз ярдәмнәре вә нигъмәтләре өчен без Аллаһы Тәгаләгә һәрдаим шөкер кылырга тиешбез.

### Шөкер өч төрле була:

**1. Калеб, ягъни йөрәк белән шөкер итү.**

Һәр нигъмәтнең Аллаһы тарафыннан бирелгәненә чын йөрәктән ышанырга кирәк. Безгә ирешкән нигъмәтләрнең барысы да Аллаһыдандыр. Моңа ышанган мөэмин-мөселман нигъмәткә вә байлыкка ирешсә, Аллаһы юлыннан бервакытта да тайпылмас, бу нигъмәтләрнең Аллаһыдан килгәнен онытмас. Нигъмәте арткан саен шөкере дә арта барыр. Нигъмәткә шөкер итү нигъмәтне арттырыр. Нигъмәтнең кыйммәтен белмәү нигъмәтнең исраф булуына сәбәп булыр. Коръәндә Аллаһы Тәгалә түбәндәгечә кисәтә:

**«Әгәр сез биргән нигъмәтләремә шөкер итсәгез, Мин ул нигъмәтләрне арттырырмын. Әгәр көферлек кылсагыз, нигъмәтләремнең кадерен белмәсәгез, минем газабым бик катыдыр».**

«Ибраһим», 14:7

**2. Тел белән шөкер итү.**

Һәр нигъмәтнең Аллаһыдан килгәнен кабул итеп, тел белән шөкер әйтү тиешледер. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер хәдисендә: «Аллаһы Үзенең колына бер нигъмәт бирсә һәм ул «әлхәмдүлилләһ» дисә, бу нигъмәтнең шөкерен үтәгән булыр. Кол икенче мәртәбә «әлхәмдүлилләһ» дисә, Аллаһы Тәгалә ул кешенең савабын арттырыр. Өченче мәртәбә «әлхәмдүлилләһ» дисә, Аллаһы ул кешенең гөнаһларын гафу итәр», – дип әйтә.

Кеше шөкер кылса, Аллаһы аның күңеленә канәгатьлек, тормышына рәхәтлек вә тынычлык бирер. Шөкер кылмаучылар күпме баесалар да, күңелләре кайгыдан котылмас, чөнки шөкерсез малның вә шөкерсез гомернең бәрәкәте булмас.

**3. Әгъзалар белән шөкер итү.**

Әгъзалар белән шөкер кылу – ул Аллаһыга гыйбадәт кылу, Аллаһының диненә хезмәт итүдер. Намаз уку, ураза тоту, хаҗ кылу кебек гыйбадәтләр белән бергә Аллаһының динен аңлату, тарату һәм бу юлда хезмәт итү дә әгъзаләр белән белдерелгән бер шөкердер.

Шөкер – пәйгамбәрләрнең вә фәрештәләрнең, Аллаһының сөекле колларының гадәтләреннәндер. Шөкерне торган саен арттыра барырга кирәк, чөнки нигъмәтнең исраф булмавына ярдәм иткән иң мөһим нәрсә – шөкердер. Шөкер кылучы һичбер вакыт Аллаһыны онытмас. Андый кеше дөньядагы нигъмәтләре белән тәкәбберләнеп, кешеләргә өстен карамас, беркемне дә түбән күрмәс. Нигъмәт ягыннан үзеннән түбәнрәк булган кешеләрнең хәленә карап, алардан гыйбрәт алыр, үзенең хәленә шөкер итәр.

# Олыларга хөрмәт, сабыйларга сөю

Барлыклар арасындагы иң өстене, иң шәрәфлесе – кеше. Аллаһы Тәгалә бу турыда Коръәндә болай дип әйтә:

**«Без кешене иң мөкәммәл рәвештә бар иттек, яраттык».**

«Тин / Инҗир», 95:4

Ислам галимнәре: «Кешегә карасаң, Аллаһының кодрәтен, бөеклеген күрерсең, чөнки кеше кебек мөкәммәл шундый мәхлүкъны бары тик Аллаһы Тәгалә генә ярата, бар итә ала», – дигән.

Аллаһы кешене хөрмәт белән бар иткән. Фәрештәләр, кеше яратылгач, Аллаһы әмере белән аңа сәҗдә кылган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә һәрвакыт кешеләрне хөрмәтли, аларга хөрмәт кылуны нәсыйхәт итә торган булган. Бер хәдисендә ул болай дигән: «Олыларга хөрмәт, кечеләргә шәфкать күрсәтмәгән кеше бездән түгел».

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кешеләрне бик яраткан, аларга һәрвакыт шәфкать вә мәрхәмәт күрсәткән. Аның якын сәхабәләреннән булган Әнәс галәйһиссәлам болай дигән: «Мин Пәйгамбәребезгә ун ел хезмәт кылдым. Бер мәртәбә дә ямьсез сүз сөйләгәнен ишетмәдем. Аның бер генә тапкыр да “бу эшне ник болай эшләдең”, дип ачуланганы булмады».

Берзаман Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә болай дигәннәр: «Әй Аллаһының Илчесе, дошманнарыңа ләгънәт укы. Аллаһы аларга бәла-каза китерсен. Аллаһы аларга җәзасын бирсен». Пәйгамбәребез аларга: «Мин кешеләргә ләгънәтче буларак түгел, ә рәхим-рәхмәт кылучы буларак җибәрелдем», – дип җавап биргән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дус-ишләрен вә танышларын ярата, картларны хөрмәт итә торган булган. Олыларны хөрмәт итү савап китерер, дөнья тормышыбызның тынычлыгын арттырыр. Аллаһы Тәгалә ихлас күңелле олыларның догаларын ишетеп, кешеләргә мәрхәмәт кылыр һәм ризыкларыбызны бәрәкәтләндерер. Мәҗлесләрнең берсендә Пәйгамбәребезгә бер чынаяк ширбәт тәкъдим иткәннәр. Пәйгамбәребез, үз чиратында, ширбәтне үзеннән өлкәнрәк булган Әбү Гобәйдә исемле сәхабәгә тәкъдим иткән. Әбү Гобәйдә: «Әй Аллаһының Илчесе, беренче булып син эч. Син миннән лаеклырак, син бит Пәйгамбәр!» – дигәч, Пәйгамбәребез: «Юк, син эч. Бәрәкәт картларыбыздадыр», – дигән, вә беренче итеп ширбәтне үзеннән өлкән булган Әбү Гобәйдәгә эчерткән.



### Пәйгамбәребез һәм балалар

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам балаларны да бик яраткан һәм башкаларга да аларны яратырга кушкан. Балаларны күрсә, мөбарәк йөзе нурланып, аларны кочаклый торган булган. Урамда очрашкан балалар белән сәламләшә, алар белән әңгәмә корып, вакыт-вакыт аларга кызыклы хәлләр дә сөйли торган булган. Дөягә атланып барган чагы булса, аларны дөясенә атландырган. Хәтта бер заман балалар белән ярышта катнашып аларны шатландырган. Усамә бине Зәйд тарафыннан китерелгән бер хәдистә: «Пәйгамбәребез галәйһиссәлам мине бер тезенә, оныгы Хәсәнне икенче тезенә утырта иде һәм безне кочаклап: «Аллаһым, боларга мәрхәмәт әйлә, тәүфыйклы, бәхетле кыл. Мин боларның хәерле һәм бәхетле булуларын телимен», – дип дога кыла иде», – дип тапшырыла.

Сабый балалар – дөнья тормышының бизәге, өлкәннәр – дөнья тормышының бәрәкәте. Шуның өчен дә сабый балаларга шәфкать, сөю, өлкәннәргә хөрмәт күрсәтү динебезнең нигез ташларыннан санала.

**■ Сәхифә “Ислам дине нигезләре” китабыннан файдаланып әзерләнде**

# ӘНИ димим…



Өстәл уртасындагы зур тортка кадап куелган кечкенә шәмнәрне нигәдер санарга керешкән Айсылу ханым гаҗәпләнүдән, аһ итте: егерме дүрт урынына егерме биш шәм балкып утыра икән! Каян килеп кергән соң әле ул? Артык шәмне алырга сузылган кулы исә һавада эленеп калды. Юк, аны алсаң, татлы сарайның бөтенлеге, матурлыгы югала икән бит! Калсынсана, хәерлегә генә булсын, дип уйлап куйды Айсылу һәм, өр-яңа тәти күлмәк киеп көзге алдында боргаланучы кызына сөеп карап, шахмат тактасыннан аерыла алмаган улларын ашыктыра башлады:

— Җәһәтрәк булыгыз, балалар. Озакламый кунаклар да килер…

Теле бер нәрсә сөйләде, ә хәтерендә, никтер, моннан нәкъ тугыз ел элек булган вакыйгалар яңарды. Әйтерсең алар, менә бүген генә булгандай, бөтен ваклыклары белән күз алдына килеп бастылар. Әйе, гаҗәеп сәер, аңлаешсыз һәм серенә хәзер дә төшенеп җитә алмаган вакыйгалар иде шул алар.

…Айназга өч яшь тулган көн. Төшендә үзе кадәр уенчык песи күргән икән кызчык. Әле җитмәсә, ул песи, ямь-яшел күзләрендә очкыннар биетеп: «Минем исемем — Куян, мин сиңа кунакка киләм, каршы ал!» – дип тә әйткән икән.

— Әни, шул песи килер микән? – диде Айназ, әнисенә сырпаланып.

— Кунак булып кына килмәс, аны үзебез барып алырбыз, бөтенләйгә үк үзебездә калыр, яме, кызым, – дигән иде Айсылу ханым.

И сөенгән иде сабый, кулларын чәбәкли-чәбәкли сикергәләгән иде:

— Минем Куяным була, минем песием була! Әнием, бүген үк барып алабызмы?

«Балалар дөньясы» кибетендә беренче күргән песигә чат ябышты Айназ:

— Әнием, менә ул Куян!

Шатлыктан кызчыкның алтынсу бөдрәләренә кадәр көлә иде сыман. Ул зәңгәрсу бөдрә тунлы, койрык очы бантиклы, үзе хәтле уенчык песине кочаклап та алды һәм дөньясын да онытты. Бу Куян нәкъ шул төшендә күргән песи икән бит!

Куян өчен һәм Айвазга алган «КамАЗ»га акча түләп торганда, Айсылу үзенә текәлгән нәни малайга игътибар итте. Бала күз явын алырлык тәтиләргә дә, шул уенчыклар тирәсендә бөтерелгән яшьтәшләренә дә карамый. Ул бары тик, алларына чыга-чыга, хатын-кызларның йөзләренә текәлә, кемнедер ашыгып эзли шикелле. Малай әлегә еламый, әмма болыт төсле күксел-зәңгәр күзләре мөлдерәгән, менә-менә «яңгыр» башланыр кебек иде.

Ул арада бала, чарасызлыктан арып, тәтиләр тирәсенә лып итеп утырды да кычкырып елый башлады. Уенчыклар бүлегендәге күңелле шау-шу кинәттынып калды. Нәниләр дә, олылар да малайга борылдылар. Аның янына сатучы хатын белән бер үк вакытта килеп җиткән Айсылу баланың җитендәй аксыл чәчләреннән сыйпап алды.

— Нигә елыйсың, акыллым, елама. Син зур малай бит инде, – диде ул, баланы тынычландырырга тырышып.

— Әниемне югалттым, – диде дә малай үксүеннән тыела алмыйча һәм һич көтмәгәндә Айсылуның итәгенә капланды.

— Хәзер табабыз әниеңне, ул үзе дә сине эзли-эзли йөдәгәндер инде…

Кибет директоры бүлмәсенә малайны өчәүләп: кызы Айназ, улы Айваз һәм Айсылу бергәләп озаттылар. Әниләренә сыенган балаларны күреп, малай тагын үкси башлады. Аны юата-юата, әнисен көтә-көтә шактый вакыт үтте, кибет радиоузелыннан кабат-кабат әйтүгә карамастан, малайны эзләп килүче күренмәде.

Ләкин болай озак торып булмый иде. Айназның туган көненә чакырылган кунаклар җыелыр чак җиткән, кайтырга ашыктылар. Ишектән чыгышлый, Айсылу ханым малайга тагын әйләнеп карады, кәнәфи почмагына елышкан сабый тәрәзәгә багып тынып калган иде…

Ә өйдә бәйрәм! Әтиләре өстәл әзерләп өлгергән, балалар, кошчыклардай чыркылдашып, Айназны сырып алдылар; китте көлеш, котлау, җыр-бию, күңелле уеннар! Кызы белән улының бәхет балкыган йөзләренә караган саен, Айсылуның күз алдына кәнәфи почмагына сыенып елаган малай килде.

…Тәмледән-тәмле ризыклардан рәхәтләнеп бушап калган савытларны юганда да, бәйрәм ыгы-зыгысыннан йончыган бүлмәләрне җыештырганда да малайны онытмадылар.

— Ул үзенә өч яшь икәнен әйтә дә белми, менә болай итеп кенә күрсәтә, – дип тәтелдәде Айназ, нәни бармакларын тырпайтып.

– «Ш» хәрефен дә дөрес әйтә алмый икән, исемен «Саса» диде, – дип дәвам итте Айваз һәм бик белдеклеләнеп өстәп тә куйды, – әле фамилиясен дә белми, әтисенең исемен – «папа», әнисенекен «мама» дип әйтте!

Айсылуның күңеле тыныч түгел иде. «Балаңны югалтсаң, акылыңнан язарсың», – дип кызганды ул Сашаның әнисен. Ахырда түзмәде, балаларын йокларга яткыруны иренә калдырып, шәһәр үзәгенә урнашкан зур кибеткә йөгерде.

Кабинетта бер милиционер белән директордан гайре беркем дә юк, алар исә малайның әнисе килер дип һаман да өметләнәләр иде күрәсең, ишек ачылганга икесе берьюлы борылып карадылар.

Курчак кебек итеп затлы чит ил киемнәренә киендерелгән бу сабый да кемнеңдер кадерлесе, багалмасы бит. Айсылу бәгырен кисеп узган шушы уйдан айный алмый интекте. Тик малайдан сораштыру бернинди нәтиҗә бирмәгән. Ул бары үзләренең машина белән «озак-озак» килгәннәрен генә әйтә алган.

Шәһәргә кич килде, урамнарны караңгылык пәрдәсе чорнап алды. «Балалар дөньясы»ның этажларында да бер-бер артлы утлар сүнә башлады. Кибет ябылыр вакыт җитте. Табылдыкны кая куярга да белмәгән директор белән милиционерны гаҗәпкә калдырып, Айсылу баланы җитәкләп алды да ишеккә таба атлады.

— Хәзергә бездә торып торсын, әти-әнисенә эзләп табу да уңайрак булыр, – диде ул, үзенең тәвәккәллегенә үзе шаккатып.

Шул ук кичне телевизордан табылдык малайны күрсәттеләр, аны кайдан эзләргә мөмкинлекне тәгаенләп, Айсылуларның адресы әйтелде.

…Йокларга яткырыр алдыннан Сашаны юындырганда, күлмәгенең эчке кесәсеннән кат-кат бөкләп тыгып куелган 100 долларлык кәгазьне табып алгач, Айсылу тынсыз калды. Димәк, сабыйны махсус адаштырып калдырганнар!

Көне буе үксеп хәлсезләнгән бәләкчне елый-елый юындырды да Айсылу, төшендә дә вакыт-вакыт сулкылдап куйган баланы кочагына кысып, төне буе күз дә йоммады.

*хикәянең дәвамы киләсе санда*

**Нурзилә (Нурзидә Нотфуллина)**

### ДҮШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Шекер Хужа
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 МИМ
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Хикмәтле хикәяләр
11:45 Җан авазы
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 Исламские финансы
12:50 Поучительные истории
13:00 «Малец-Удалец» мультфильм
13:15 «Шекер Хужа» мультфильм
13:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 Шекер Хужа
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 МИМ
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Хикмәтле хикәяләр
20:45 Җан авазы
21:00 Сказки снов
21:10 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Шекер Хужа
21:40 Исламские финансы
22:00 Учимся читать намаз
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым Поучительные истории
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

### СИШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Хәзинә
08:20 Җан авазы
08:30 1001 хәзинә
08:45 «Таз Малай» мультфильм
09:00 Шокер Хужа
09:10 Балам-багалмам
09:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:50 Хикмәтле хикәяләр
10:00 Намазга өйрәник
10:30 Тәфсир дәресләре Тимергали Юлдашев
11:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:15 Гаилә дәресләре
11:40 Мукабаля (Чтение Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Хузур вояж с Антоном Кротовым
12:30 Шекер Хужа
12:40 «Малец-Удалец» мультфильм
13:00 Ученые Ислама
13:20 Ислам без стереотипов
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәзинә
17:20 Җан авазы
17:30 1001 хәзинә
17:45 «Таз Малай» мультфильм
18:00 Шокер Хужа
18:10 Балам-багалмам
18:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:50 Хикмәтле хикәяләр
19:00 Намазга өйрәник
19:30 Тәфсир дәресләре Тимергали Юлдашев
20:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:15 Гаилә дәресләре
20:45 Мукабаля (Чтение Корана)
21:00 Сказки снов
21:10 Ученые ислама
21:30 Шекер Хужа
21:40 «Малец-Удалец» мультфильм
22:00 Мастерская мусульманки
22:10 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
22:30 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### ЧӘРШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Шекер Хужа
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 МИМ
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Хикмәтле хикәяләр
11:45 Җан авазы
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 Исламские финансы
12:50 Поучительные истории
13:00 «Малец-Удалец» мультфильм
13:15 «Шекер Хужа» мультфильм
13:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 Шекер Хужа
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 МИМ
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Хикмәтле хикәяләр
20:45 Җан авазы
21:00 Сказки снов
21:10 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Шекер Хужа
21:40 Исламские финансы
22:00 Учимся читать намаз
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым Поучительные истории
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

### ПӘНҖЕШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Хәзинә
08:20 Җан авазы
08:30 1001 хәзинә
08:45 «Таз Малай» мультфильм
09:00 Шокер Хужа
09:10 Балам-багалмам
09:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:50 Хикмәтле хикәяләр
10:00 Намазга өйрәник
10:30 Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев
11:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:15 Гаилә дәресләре
11:40 Мукабаля (Чтение Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Хузур вояж с Антоном Кротовым
12:30 Шекер Хужа
12:40 «Малец-Удалец» мультфильм
13:00 Халяль-лайфстайл
13:20 Ислам без стереотипов
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәзинә
17:20 Җан авазы
17:30 1001 хәзинә
17:45 «Таз Малай» мультфильм
18:00 Шокер Хужа
18:10 Балам-багалмам
18:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:50 Хикмәтле хикәяләр
19:00 Намазга өйрәник
19:30 Тәфсир дәресләре Тимергали Юлдашев
20:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:15 Гаилә дәресләре
20:45 Мукабаля (Чтение Корана)
21:00 Сказки снов
21:10 Халяль-лайфстайл
21:30 Шекер Хужа
21:40 «Малец-Удалец» мультфильм
22:00 Мастерская мусульманки
22:10 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
22:30 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### ҖОМГА

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Шекер Хужа
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 МИМ
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 «Минбар» Җомга вәгазе
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 Исламские финансы
12:50 Поучительные истории
13:00 «Малец-Удалец» мультфильм
13:15 «Шекер Хужа» мультфильм
13:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 Шекер Хужа
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 МИМ
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 «Минбар» Җомга вәгазе
21:00 Сказки снов
21:10 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Шекер Хужа
21:40 Исламские финансы
22:00 Учимся читать намаз
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым Поучительные истории
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

### ШИМБӘ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 МИМ
08:30 Балам-багалмам
08:50 Хикмәтле хикәяләр
09:00 «Таз Малай» мультфильм
09:15 Һөнәрләр
09:30 Хәзинә
09:45 Шекер Хужа
10:00 Намазга өйрәник
10:30 Әлифба сабаклары
10:45 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:00 «Мәслихәт»
11:20 Хәдис дәресләре
11:40 Җан авазы
11:50 Мукабаля (Чтение Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Хузур вояж с Антоном Кротовым
12:30 Шекер Хужа
12:40 «Малец-Удалец» мультфильм
13:00 Халяль-лайфстайл
13:20 Ислам без стереотипов
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 МИМ
17:30 Балам-багалмам
17:50 Хикмәтле хикәяләр
18:00 «Таз Малай» мультфильм
18:15 Һөнәрләр
18:30 Хәзинә
18:45 Шекер Хужа
19:00 Намазга өйрәник
19:30 Әлифба сабаклары
19:45 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:00 «Мәслихәт»
20:20 Хәдис дәресләре
20:40 Җан авазы
20:50 Мукабаля (Чтение Корана)
21:00 Сказки снов
21:10 Халяль-лайфстайл
21:30 Шекер Хужа
21:40 «Малец-Удалец» мультфильм
22:00 Мастерская мусульманки
22:10 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
22:30 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### ЯКШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 МИМ
08:30 «Мәслихәт»
08:50 «Рисалә» Каюм Насыйри
09:00 «Таз Малай» мультфильм
09:15 Шекер Хужа
09:30 Һөнәрләр
09:45 Хәзинә
10:00 Намазга өйрәник
10:30 Хәдис дәресләре
10:50 Бер хәдис- бер җавап
11:00 «Минбар» Җомга вәгазе
11:30 Әлифба сабаклары
11:50 Хикмәтле хикәяләр
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 Исламские финансы
12:50 Поучительные истории
13:00 «Малец-Удалец» мультфильм
13:15 «Шекер Хужа» мультфильм
13:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 МИМ
17:30 «Мәслихәт»
17:50 «Рисалә» Каюм Насыйри
18:00 «Таз Малай» мультфильм
18:15 Шекер Хужа
18:30 Һөнәрләр
18:45 Хәзинә
19:00 Намазга өйрәник
19:30 Хәдис дәресләре
19:50 Бер хәдис- бер җавап
20:00 «Минбар» Җомга вәгазе
20:30 Әлифба сабаклары
20:50 Хикмәтле хикәяләр
21:00 Сказки снов
21:10 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Шекер Хужа
21:40 Исламские финансы
22:00 Учимся читать намаз
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым. Поучительные истории
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

## ТҖ мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты «Дозволенное и запретное в питании и не только (Пособие по фикһу)» китабын бастырды.




ТҖ мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты ТҖ ҮДОсы МДНнең "Хәләл" Комитеты белән берлектә «Дозволенное и запретное в питании и не только (Пособие по фикһу)» ("Ризыкта һәм башка мәсьәләләрдә рөхсәт итүләр һәм тыюлар" (Фикһ буенча ярдәмлек)" китабын бастырды.

Әлеге китапта фикһның төп принциплары, шәригать буенча рөхсәт ителгән хайваннар һәм эчемлекләр, ислам кагыйдәләре буенча хайваннарны сую, дуңгыз итенең ризыкларда һәм халык кулланылышындагы товарларда булуы, бизәнү әйберләре продукциясе темалары һәм актуаль сорау-җаваплар яктыртылган.

Мөселманнар хәләллек мәсьәләсендәге сораулардагы мөһим карашларны белергә һәм дөрес итеп кулланырга тиеш. Шунысын белү кирәк: динебезнең таләпләре камил һәм аларны үтәү ике дөньяда да бәхеткә һәм уңышка ирешүгә китерә, чөнки әлеге таләпләр Раббыбыздан. Китап киң катлау укучылары өчен кызыклы һәм файдалы.

**Китапны "Хозур" нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.**
**Кибет:** Казан шәһ., Тукай ур., 36нчы йорт.
Тел.: +7(903) 305-45-43
**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.
Тел.: +7 (966) 250-00-09
**Интернет-кибет:** huzurshop.ru (http://huzurshop.ru/)





## « Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2020 елның икенче яртыеллыгына язылу башланды

- Ярты елга язылу бәясе: 156 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин:
podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru
сайтының «Подписка» бүлегендә.

дин вә мәгыйшәт

Белешмәләр өчен телефон:
+7 (843) 598 09 42


### КАЗАН ӨЧЕН ИЮНЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Сәхәр тәмам/ иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.06.2020 | 01:06 | 03:06 | 12:00 | 17:24 | 20:17 | 21:47 |
| 02.06.2020 | 01:05 | 03:05 | 12:00 | 17:25 | 20:18 | 21:48 |
| 03.06.2020 | 01:04 | 03:04 | 12:00 | 17:25 | 20:19 | 21:49 |
| 04.06.2020 | 01:03 | 03:03 | 12:00 | 17:26 | 20:20 | 21:50 |
| 05.06.2020 | 01:02 | 03:02 | 12:00 | 17:27 | 20:21 | 21:51 |
| 06.06.2020 | 01:02 | 03:02 | 12:00 | 17:27 | 20:23 | 21:53 |
| 07.06.2020 | 01:01 | 03:01 | 12:00 | 17:28 | 20:24 | 21:54 |
| 08.06.2020 | 01:00 | 03:00 | 12:00 | 17:29 | 20:25 | 21:55 |
| 09.06.2020 | 01:00 | 03:00 | 12:00 | 17:29 | 20:25 | 21:55 |
| 10.06.2020 | 00:59 | 02:59 | 12:00 | 17:30 | 20:26 | 21:56 |
| 11.06.2020 | 00:59 | 02:59 | 12:00 | 17:30 | 20:27 | 21:57 |
| 12.06.2020 | 00:58 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:28 | 21:58 |
| 13.06.2020 | 00:58 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:29 | 21:59 |
| 14.06.2020 | 00:58 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:29 | 21:59 |
| 15.06.2020 | 00:58 | 02:58 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 16.06.2020 | 00:57 | 02:57 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 17.06.2020 | 00:57 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 18.06.2020 | 00:57 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 19.06.2020 | 00:57 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 20.06.2020 | 00:58 | 02:58 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 21.06.2020 | 00:58 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 22.06.2020 | 00:58 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 23.06.2020 | 00:58 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 24.06.2020 | 00:59 | 02:59 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 25.06.2020 | 00:59 | 02:59 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 26.06.2020 | 01:00 | 03:00 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 27.06.2020 | 01:00 | 03:00 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 28.06.2020 | 01:01 | 03:01 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 29.06.2020 | 01:02 | 03:02 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 30.06.2020 | 01:02 | 03:02 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |


ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
*Май саны, №5 (298)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2749
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 26 нчы майда таратыла.
График буенча бу санга 25 нче май көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.